Шәһәр тибындагы Түбән Мактама бистәсе
"63-нче катнаш төрдәге "Баланым" балалар бакчасы МБМББУ" мөдире вазифаларын башкаручы боерыгы нигезендә гамәлгә кертелде
№117 от «01» 09 2022ел

Раслыйм
Шәһәр тибындагы Түбән Мактама бистәсе
"63-нче катнаш төрдәге "Баланым" МБМББУ"
мөдире вазифаларын башкаручы
______ /Багаева О.В./

Педагогик киңәшмәдә каралган һәм расланган.
Беркетмә № 1
«31» 08 2022ел

**Шәһәр тибындагы Түбән Мактама бистәсе**
**"63-нче катнаш төрдәге "Баланым" балалар бакчасы МБМББУ"**
**балаларга татар теле өйрәтүче тәрбиячесенең эш программасы**

2022-2023 уку елына

Төзеде: татар теле тәрбиячесе
Хасаншина Г.М

# ЭЧТӘЛЕК


| I НЧЕ БҮЛЕК. Максат | | Битләр |
|---|---|---|
| 1.0 | Аңлатма язуы. Норматив-хокукый документлар. | 3-4 |
| 1.1 | Программаның максаты һәм бурычлары | 4 |
| 1.2 | Программа принциплары | 4-6 |
| 1.3 | Милли состав | 7 |
| 1.4 | Программа үзләштерүдә көтелгән нәтиҗәләр | 7-8 |
| 1.4.1. | “Татарча сөйләшәбез”, “Минем өем” проекты, 4-5 яшь | 8 |
| 1.4.2. | “Татарча сөйләшәбез”, “Уйный-уйный үсәбез” проекты, 5-6 яшь | 8-9 |
| 1.4.3. | “Татарча сөйләшәбез”, “Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар” проекты, 6-7 яшь | 9 |
| II НЧЕ БҮЛЕК. Эчтәлек | | |
| 2.1 | Балага үсеш юнәлеше буенча белем бирү | 10-13 |
| 2.2 | Белем бирүдә эш төрләре һәм формалары | 13 |
| 2.3 | Комплекслы-тематик план | 13 |
| 2.3.1. | “Татарча сөйләшәбез”, “Минем өем” проекты, 4-5 яшь | 13-18 |
| 2.3.2. | “Татарча сөйләшәбез”, “Уйный-уйный үсәбез” проекты, 5-6 яшь | 18-22 |
| 2.3.3. | “Татарча сөйләшәбез”, “Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар” проекты, 6-7 яшь | 23-27 |
| 2.3.4. | “Туган телдә сөйләшәбез”, 2-3 яшь | 28-30 |
| 2.3.5. | “Туган телдә сөйләшәбез”, 3-4 яшь | 30-32 |
| 2.3.6. | “Туган телдә сөйләшәбез”, 4-5 яшь | 32-34 |
| 2.3.7. | “Туган телдә сөйләшәбез”, 5-6 яшь | 34-36 |
| 2.3.8. | “Туган телдә сөйләшәбез”,6-7 яшь | 36-38 |
| 2.4 | Еллык план | 39-42 |
| III НЧЕ БҮЛЕК. Оештыру | | |
| 3.1 | Материаль-техник яктан тәэмин ителеш | 42 |
| 3.2 | Үстерешле-предметлы тирәлекне оештыру | 42-47 |
| 3.3 | Программалар һәм методик яктан тәэмин ителеш | 47 |
| 3.4 | Тәрбиячене̧ң эш көне бүленеше (Циклограмма) | 47-49 |
| 3.5 | Белем бирү эшчәнлек челтәре | 50 |
| 3.6 | Кулланылган әдәбият | 50 |
| КУШЫМТА | | |
| Диагностика | | 51-64 |

# I НЧЕ БҮЛЕК. Максат
## 1.3 Аңлатма язуы.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә кабул ителгән 2010 – 2015 елларда мәгарифне үстерү стратегиясендә (30.12.2010, №1174) – мәктәпкәчә тәрбия һәм белем бирү учреждениеләре өчен рус һәм башка милләт балаларын татарча сөйләшергә өйрәтү программасы, укыту-методик комплектлары (УМК) төзелде.

Программа 4 яшьтән 7 яшькә кадәр булган рус телле балаларның татарча аралашырга өйрәтү эшчәнлекләрен, “Минем өем” (4-5 яшь), “Уйный – уйный үсәбез” (5-6 яшь), “Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар” (6 – 7 яшь) проектларын үз эченә ала. Программа мәктәпкәчә яшьтәге баланың үсеш закончалыкларына, шәхси һәм эшлекле якын килү турындагы фундаменталь тикшеренүләргә, тел өйрәтү процессында методик стандарт итеп кабул ителгән коммуникатив технология принципларына, сөйләм барлыкка килү концепциясенә (Л. С. Выготский, В. В. Давыдов, Е. И. Пассов, П. Я. Гальперин), гамәли эшкәртмәләр һәм методик киңәшләргә, мәктәпкәчә мәгариф системасы эшчәнлеген ачыклаучы норматив хокукый актлар, нигезләмәләренә көйләнгән.

Балаларны татар телендә сөйләшергә һәм аралашырга өйрәтү билгеле бер күләмдәге сүз байлыгы булдырудан башлана. Аралашуга чыгу өчен нәтиҗәле чаралар булып аудиоязмалар, эш дәфтәрләре, анимацион сюжетлар, интерактив уеннар тора.

Яңа сүз өйрәткәндә, сүзләр тизрәк истә калсын өчен сүз кат-кат әйттерелә, аңлашылмаган очракта, аның русча тәрҗемәсе бирелә; төрле эш формаларында (пышылдап, күмәкләп, төркемнәргә бүленеп, хәрәкәтләнеп әйтеп) өйрәтелә; уеннар кулланып (“Ватык телефон”, “Кайтаваз”...) ныгытыла; хәтердә калдыру максатыннан төрле уеннар оештырыла: “Исемен әйтсәң бирәм”, “Мин күрсәтәм, син әйт”, “Сорап ал”, “Серле кәрзин”.

Өйрәнгән лексиканы сөйләмдә кулланганда “Бу кем?”, “Кем юк?”, “Кәрзиндә нәрсә бар?”, “Нәрсә юк?”, “Серле янчык”, “Әйе-юк”, “Дөресен әйт” дидактик уеннары уйнала.

Аралаша белү күнекмәләре булдырганда “Әйдәгез танышабыз”, “Кунакны сыйла”, “Кибеттә”, “Кафеда”, “Телефоннан сөйләшү”уен ситуацияләре оештырыла.

Пиктограммалар мәктәпкә әзерлек төркемендә, яңа сүзләр (фигыльләр) белән беренче тапкыр таныштырганда гына кулланыла.

Тәрбияче сүзлек белән эшләгәндә татар һәм рус телләре өчен уртак сүзләргә таяна ала.

Укыту-методик комплекты кысаларында, лексик минимумны үзләштергән очракта, эшчәнлектә планлаштырылган уеннарның эчтәлеген үзгәртү, яңа алымнар кертү, баету хуплана.

Төркемнәрдә балаларның һәм тәрбиячеләрнең татар телендә аралашулары һәрдаим булырга тиеш. Эшчәнлектә өйрәнелгән тел материалы, режим моментларында, уен эшчәнлеге аша (ситуатив күнегүләр, сюжетлы рольле уеннар, үстерелешле диалоглар, сәхнәләштерү һ. б.) ныгытыла.

Рус телле балаларны татарча сөйләшергә өйрәткәндә балалар бакчасы коллективы һәм әти-әниләрнең бердәм позициядә булуы уңай нәтиҗә бирә.

**Норматив – хокукый документлар:**

Федераль дәрәҗәдә:

• Федеральный Закон Российской Федерации «Об образовании в РФ» от 29.12.2012 №273

• Приказ Минобрнауки РФ от 17 октября 2013 г. № 1155. Зарегистрирован в Минюсте России 14 ноября 2013 г., регистрационный №30 384 «Об утверждении Федерального государственного образовательного стандарта дошкольного образования»

•Приказ Минобрнауки «Об утверждении Порядка разработки примерных основных образовательных программ, проведения их экспертизы и ведения реестра примерных основных образовательных программ» от 28 мая 2014года, № 594

• Постановление Главного государственного санитарного врача РФ от 28.09.2020г. № 28) СанПиН 2.4.3648-20 «Санитарно-эпидемиологические требования к организации воспитания и обучения, отдыха и оздоровления детей и молодежи»

• Постановление Главного государственного санитарного врача РФ от 28.01.2021г. №2 "Об утверждении санитарных правил и норм СанПиН 1.2.3685-21 "Гигиенические нормативы и требования к обеспечению безопасности и (или) безвредности для человека факторов среды обитания" (вместе с "СанПиН 1.2.3685-21. Санитарные правила и нормы...")
• Приказ Минтруда России №544н от 18 октября 2013 г. Об утверждении профессионального стандарта «Педагог (педагогическая деятельность в сфере дошкольного, начального общего, основного общего, среднего общего образования) (воспитатель, учитель)». Зарегистрировано в Минюсте 6 декабря 2013, № 30550;
• Приказ от 30 августа 2013 года N 1014 Об утверждении Порядка организации и осуществления образовательной деятельности по основным общеобразовательным программам – образовательным программам дошкольного образования;
• Приказ Минтруда России №544н от 18 октября 2013 г. Об утверждении профессионального стандарта «Педагог (педагогическая деятельность в сфере дошкольного, начального общего, основного общего, среднего общего образования) (воспитатель, учитель)». Зарегистрировано в Минюсте 6 декабря 2013, № 30550;

Республика дәрәҗәсендә:
• Закон Республики Татарстан от 22 июля 2013 г. № 68-ЗРТ «Об образовании»
• Закон Республики Татарстан «О языках народов Республики Татарстан» № 1560-XII от 8 июля 1992 года

Учреждения дәрәҗәсендә:
• Устав МБДОУ «Д/с № 63 «Калинка»;
• Годовой план работы на текущий учебный год.

## 1.3 Программаның максаты һәм бурычлары.

| **УМК «Туган телдә сөйләшәбез”- татар балаларына ана теле өйрәтү** | **УМК “ Татарча сөйләшәбез”- рус балаларына татар теле өйрәтү** |
|---|---|
| **1.3 Программаның максаты:** балаларга туган телне өйрәтү, сөйләм үстерү, әдәби телдә сөйләшү күнекмәләре булдыру.<br>**Программаның бурычлар:**<br>1. Балаларга ана телендә дөрес һәм яхшы итеп сөйләшергә өйрәтү.<br>2. Тел системасының фонетик, лексик, грамматик төзелеше дәрәҗәләрен формалаштыру.<br>3. Бәйләнешле сөйләм үстерү.<br>4. Тел һәм сөйләм күренешләрен аңлау сәләте булдыру.<br><br>**1.2 Программаның принциплары:**<br>1. Үстерелешле өйрәтү;<br>2. Өйрәтү барышында тәрбияләү;<br>3. Фәннилек;<br>4. Эзлеклелек һәм системалылык;<br>5. Аңлаешлылык;<br>6. Балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алу;<br>7. Гуманлылык;<br>8. Күрсәтмәлелек. | **1.1 Программаның максаты:** Информацион-коммуникатив технологияләр, уен-ситуаөияләр, күргәзмәлелек кулланып тел өйрәнү, аралашу теләге тудыру.<br>**Программаның бурычлар:**<br>1. Сүз байлыгы булдыру.<br>2. Гади диалогта катнаша белү, сүзләрне отып алу аша хәтер, зиһен үстерү.<br>3. Татар теленә кызыксыну уяту.<br><br>**1.2 Программаның принциплары:**<br>1.Коммуникативлылык принцибы –балаларны татар телен аралашу чарасыбуларак куллануга әзерләүгә корылган.Телне фән буларак түгел, ә аралашу чарасыбуларак өйрәтү.<br>2. Интеграция һәм дифференциация принцибы – һәр сөйләм төренең үзүзәнчәлеген исәпкә алу, тәрбияче сөйләмен техник чаралар ярдәмендә (аудио-видеоязмада) тыңлау (аудирование), тел үзәнчәлекләрен төрле күнегүләрдә бирү, балаларның диалогик сөйләмен үстерү;<br>3.Күрсәтмәлелек принцибы – тел өйрәтүне көндәлек тормыштагы һәр төрле эшчәнлеккә |

Балалар белән эшләү процессында сүзлек эше зур урын ала. Сүзлек эше – бәйләнешле сөйләм нигезе. Балалар бакчасында сүзлек эшенең өч бурычы чишелә:

1. Иң беренче чиратта, гомумикулланылыштагы лексика хисабына (предметларны, аларның төп билгеләрен, сыйфатларын, алар белән эш-хәрәкәтләрен атау) сүзлекне баету.

2. Сүзлеккә төгәллек кертү. Балаларга сүзне әйтү үрнәген бирү, аны һәр бала белән күптапкыр кабатлау.

3. Сүзлекне активлаштыру.

Сөйләмнең грамматик төзелешен формалаштыруның төп шарты – тәрбиячинең, өлкәннәрнең грамоталы сөйләме һәм сөйләмнең морфологик, синтаксик ягын, сүзъясалу ысулларын үзләштерү буенча үткәрелә торган күнегүләр.

Аваз культурасы тәрбияләү буенча эш аның сөйләм сулышы, ишетеп кабул итү, артикуляция аппаратын үстерү һ. Б. Шундый компонентларны үз эченә ала.

Бәйләнешле сөйләм үстерү сөйләмнең ике формасын – диалоглы һәм монологлы сөйләмүстерүне күздә тота. Диалоглы сөйләм үстерүдә сорау-җавап формасы, балаларның үзләренең сорау бирә, бер-берсенә мөрәҗәгать итә белүе – иң отышлы формалар. Балаларның кечкенә хикәяләрне мөстәкыйль төзи белүе монологлы сөйләм барлыкка килүдә мөһим күрсәткеч булып тора.

Балаларны матур әдәбият һәм халык иҗаты белән таныштыру – сөйләм үсешенең әһәмиятле бурычы һәм чарасы. Матур әдәбият
һәм халык иҗаты белән таныштыру түбәндәге бурычларны чишкәндә тормышка ашырыла:

1. Дөньяны бербөтен итеп кабул итүне, күзаллауларны формалаштыру.

2. Әдәби сөйләмне үстерү.

3.Эстетик зәвыкны, әдәби әсәрне кабул итүне үстерү.

Туган телгә өйрәтү, сөйләм үстерү бурычларын чишкәндә өйрәтүнең төрле методлары, алымнары, чаралары кулланыла. Шундый чараларның берсе булып, бармак уеннары тора. Хәрәкәтләнү активлыгы югарырак булган саен, балаларның сөйләме бәйле рәвештә, аларның тирә-юньне танып белүенең төп чарасы булып торган уен аша үткәрү;

4.Тел өйрәтү, тәрбия һәм үстерүбурычларының бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә тормышка ашыру принцибы;

5.Барлык белем бирү өлкәләрен берләштерү(интегральләштерү) принцибы: аралашу, танып-белү, социальләштерү, физик культура, сәламәтлек, хезмәт, иминлек, матур әдәбият, иҗади сәнгать, музыка.

6.Дәвамчанлык принцибы – балалар бакчасыһәм башлангыч мәктәптә эзлеклелекне күздә тоту;

7.Белем бирүне комплекслы-тематикпринципкакорып оештыру;

8. Белем бирү эшчәнлегенең мотивлашканбулу принцибы – бала материалны үзе өченкызык булганда, үзенең шәхсиихтыяҗларына туры килгәндә генә кабулитә һәм фикерли башлый. Телне өйрәтүпроцессында әкияти сюжетлар карау,кызыклы таныш геройлар (Акбай, Мияу)белән очрашу, уен элементларын куллану –тел материалын өйрәнүнең мотивлашканбулуын тәэмин итә. Телне аралашу, уенситуацияләренә бәйләп өйрәнгәндә, балалартел өйрәнүнең практик әһәмиятен тоялар,эмоциональ к–тәренкелек туа һәм алар телматериалын бик теләп үзләштерәләр.

9.Белем бирү эшчәнлегенең дидактикпринцибы – гадидән катлаулыга таба бару.

10. Индивидуальләштерү принцибы – телөйрәткәндә социаль шәхес сыйфатларынүстерүне күздә тоту.Балаларның яшьүзәнчәлекләрен исәпкә алу.

**Татар телен өйрәтүдә кулланыла торган чаралар.**

1. Эшчәнлек эшкәртмәләре, диагностик материаллар.

2. Тавышлы күрсәтмәлелек (һәр проект өчен аудиоязмалар, анимацион сюжетлар, мультфильмнар).

3. Картиналы һәм картиналы-дидактик күрсәтмәлелек(таратма һәм күрсәтмә рәсемнәр, җырлы-биюле уеннар, театр эшчәнлеге өчен материаллар).

4. Символик, график күрсәтмәлелек (пиктограммалар).

5. Күләмле күрсәтмәлелек (макетлар, муляжлар, уенчыклар)

| | |
|---|---|
| тизрәк һәм яхшырак үсеш ала, сөйләм сыйфаты, төрлелеге белән аерылып тора. Бармак уеннары баш мие эшчәнлегенә,интеллект үсешенә уңай йогынты ясый. Чыннан да, физиологлар, психологлар үткәргән тикшеренүләр (Л.С. Выготский, И.П. Павлов, А.Р. Лурия, А.А. Леонтьев һ.б.) хәрәкәтләнү һәм сөйләм моторикасының үзара бәйле булуын исбатлыйлар.<br>Балалар белән эшләү дәверендә төрле предметлар тотып биюләр, уеннар киң кулланыла. Нәниләр уенчыкларны яшерәләр, эзлиләр, табалар. Мондый уеннар балаларда зур кызыксыну уята, тәрбияче күрсәткән хәрәкәтләрне балалар тырышып кабатлыйлар, “куян булып сикерәләр”, “кошлар булып очалар”, җим чүплиләр”, “аю кебек алпан-тилпән йөриләр”, “әтәч булып кычкыралар” һ.б. Бу уеннарда музыка әсәрләрен куллану балаларның фонематик ишетү сәләтен, ритмикасын, эмоциональ сферасын да баета, үстерә.<br>УМКда өч белем бирү өлкәсе каралган:<br>1.”Танып – белү” белем бирү өлкәсе табигать, аның үзенчәлекләре, экологик бәйләнешләр белән таныштыру;ел фасыллары турында белемнәрен тирәнәйтүне үз эченә алган.<br>2.”Аралашу” белем бирү өлкәсе нәниләрдәтуган телгә мәхәббәт тәрбияләү, матур әдәбият әсәрләре белән кызыксыну, авазларны дөрес әйтү, бәйләнешле сөйләм культурасы булдыру, диалогик сөйләм чараларын үз эченә алган.<br>3. “Матур әдәбият” белем бирү өлкәсе кешеләрне һәрчак яхшыга гына өнди, акыллы, тапкыр булырга киңәш итә, шигырьләр, хикәяләр, экиятләр белән таныштыруны, балаларны әдәби телдә сөйләшергә өйрәтүне максат итеп куя. | 6. Интерактив уеннар.<br>7. Эш дәфтәрләре.<br>**Эш төрләре һәм формалары.**<br>Программа бурычларын үтәүдә эш формаларының, практик гамәли алымнарның, чараларның әһәмияте зур. Төп эш төрләре булып түбәндәгеләр тора:<br>1. Предметлар белән эш: тасвирлау, уенчык белән диалог төзү, уен һәм экиятләрдә катнашу.<br>2. Рәсемнәр белән эш: тасвирлау, үстерешле диалог.<br>3. Сюжетлы-рольле уеннар;<br>4. Әйлән-бәйлән, җырлы-биюле уеннар өйрәнү (аудиоязмага таянып).<br>5. Театральләштерү, сәхнәләштерү (бармак театры, битлекләр, костюмнар, театр күрсәтү (әти-әниләргә, башка төркем балаларына).<br>6. Хәрәкәтле уеннар: туп белән уеннар, |

## 1.3 Милли состав

| Төркемнәр | Татарлар | Руслар | Катнаш гаиләләр | Үзбәк | Чуваш | Башкир | Армян | Мордвин | Барлыгы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| II кечкенәләр | 13 | 4 | 12 | 1 | | | | | 30 |
| Уртанчылар 1 | 14 | 6 | 10 | | | | | | 30 |
| Уртанчылар | 19 | 9 | | 1 | 1 | | | | 30 |
| Зурлар төркеме 1 | 16 | 8 | 6 | | | | | | 30 |
| Зурлар торкеме | 10 | 6 | 13 | | | 1 | | | 30 |
| Мәктәпкә Әзерлек төркеме | 19 | 8 | 3 | | | | | | 30 |
| Мәктәпкә әзерлек (1) төркеме | 14 | 5 | 4 | | | | 1 | 1 | 25 |
| Мәктәпкә әзерлек төркеме (логопедия) | 10 | 3 | 3 | | | | | | 16 |
| Барлыгы | 115 | 49 | 51 | 2 | 1 | 1 | 1 | 1 | 221 |

## 1.4 Программа үзләштерүдә көтелгән нәтиҗәләр

### 1.4.1. “Татарча сөйләшәбез”, “Минем өем” проекты, 4-5 яшь

**Лексик минимум** – якынча 62 сүз. “Минем өем” проекты темалары( “Гаилә”,“Ашамлыклар”,“Уенчыклар”,“Саннар”) буенча бирелгән лексиканы төрле ситуацияләрдә ишетеп аңлап куллана белергә өйрәтү, сөйләм күнекмәләрен булдыру.

Аларның тирә-юнь күзаллавын киңәйтә бару, югарыда күрсәтелгән темага караган сүзләр хисабына балаларның сүз байлыгын арттыру өстендә эшләү, аларда татар телендә сөйләшә башлау теләге уяту.

Актив үзләштерүләренә ирешү өчен әйбер исемнәренең мәгънәсен аңлату һәм аларны дөрес әйтү күнегүләре эшләү. Иң якын кешеләр (әти, әни, бабай, әби, малай, кыз), яраткан уенчыклар (туп, машина, курчак, эт, песи куян, аю), ашамлыклар (алма, ипи, сөт, чәй) һәм саннар (бер, ике, өч, дүрт, биш) хисабына сүзлекне баету һәм активлаштыру. Өйрәнгән сүзләрне аерым, күмәк, тәрбияче ярдәмендә кабатлый белү күнекмәләрен булдыру. Алма бир. Мә, алма. Бу кем? Бу нәрсә? сорауларын аңлап җавап бирергә өйрәтү.

-Бу кем? – Бу әти.

-Бу нәрсә? – Бу туп.

Нинди? соравын аңларга, дөрес җавап бирергә өйрәтү.

-Туп нинди? – Кечкенә.

-Машина нинди? – Матур.

Әйбернең билгесен ачыклау максаты белән куела торган сорауларны аңларга һәм сөйләмдә җавап кайтарырга өйрәтү. (Зур, матур, кечкенә, чиста, әйбәт, пычрак, тәмле).

-Бу нәрсә? – Бу туп.

-Туп нинди? – Туп пычрак (зур, матур, кечкенә, чиста, әйбәт).

Тәрбияче әйткән сүзләрне, кыска фразаларны балаларның кабатлап әйтә белүләренә ирешү өстендә эшләү. Аларның өлкәннәр кушкан катлаулы булмаган боерык/биремнәрне аңлап, үти белүләренә ирешү (мә, бир, утыр, аша, эч, уйна, ю, ал).

-Мә, куян. – Бир куян.

Тәрбияче әйткән билге буенча предметны табу, күрсәтә белергә өйрәтү.

Зур машина ал. Тәмле алма бир.

Үз исемен дөрес әйтә, исәнләшә, саубуллаша белергә өйрәтү, сүзләрне дөрес, урынлы куллану.

Исәнме. – Исәнмесез. Сау бул. – Сау булыгыз. Мин кыз. - Мин Оля. Мин малай - Мин Коля.

Таныш предметларның исемнәрен ныгыту, куелган сорауга раслаучы, инкарь итүче сүзләрне (әйе, юк) дөрес кулланырга өйрәтү

Син Коля? – Әйе.

Син кыз? – Юк, мин малай.

Мин, син алмашлыкларын аңларга һәм урынлы кулланырга өйрәтү.

Син кем? – Мин Коля.

Кечкенә күләмле шигырьләр, җырлар өйрәтү.

Белем бирү эшчәнлегенең нәтиҗәләре

Гаилә, уенчыклар, ашамлыклар һәм саннар хисабына сүз байлыгы бар.

Өйрәнгән сүзләрне, кыска фразаларны аерым, күмәк, тәрбияче ярдәмендә кабатлый белә.

Өлкәннәр кушкан катлаулы булмаган биремнәрне аңлап үти.

Үз исемен дөрес әйтә, исәнләшә, саубуллаша, рәхмәт әйтә белә.

Куелган сорауларны аңлап, сөйләмдә 2-3 сүз белән җавап кайтара белә.

Бер-берсе һәм өлкәннәр белән 62 сүз кулланып татар телендә аралаша.

Бирелгән лексиканы төрле ситуацияләрдә ишетеп аңлап куллана белә, сөйләм күнекмәләре бар.

Әйбер исемнәренең мәгънәсен аңлый һәм аларны дөрес әйтә белә.

Бу кем? Бу нәрсә? сорауларын аңлап, җавап бирә.

Әйбернең билгесен ачыклау максаты белән куела торган сорауны аңлый һәм сөйләмдә җавап кайтара белә.

Раслаучы, инкарь итүче сүзләрне дөрес куллана белә.

Мин, син алмашлыкларын аңлый һәм урынлы куллана.

Кечкенә күләмле шигырьләр, җырлар белә.

Татар телендә сөйләшү теләге бар.

## 1.4.2. “Татарча сөйләшәбез”, “Уйный-уйный үсәбез” проекты, 5-6 яшь

**Лексик минимум** – якынча 45 сүз. “Уйный-уйный үсәбез” проекты темалары (“Гаилә”, “Ашамлыклар”, “Уенчыклар”, “Саннар” , **“**Яшелчәләр”, “Савыт-саба”, “Киемнәр”, “Шәхси гигиена”, “Өй җиһазлары”, “Бәйрәмнәр”) буенча бирелгән лексиканы төрле эшчәнлектә (уен, аралашу, музыка, хезмәт) ишетеп аңлап куллана белергә өйрәтү, сөйләм күнекмәләрен булдыру.

Яңа сүзләр хисабына баланың сөйләмен баету, тулыландыру. (*Кишер, суган, бәрәңге, кыяр, кәбестә, аш, ботка, кашык, тәлинкә,чынаяк, күлмәк, чалбар, бит, кул, өстәл урындык, карават, баллы, ничә, нинди, алты, җиде, сигез, тугыз, ун, кызыл, сары, яшел, зәңгәр, нәрсә кирәк, юа, ки, сал, йокла, хәерле көн, яратам, бар).*

Санау күнекмәләрен ныгыту, сөйләмдә камилләштерү.

Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? соравын аңлап, мөстәкыйль рәвештә сорау куя һәм дөрес җавап бирә белергә өйрәтү.

Раслаучы һәм инкарь итүче сүзләрне ныгыту, урынлы куллану. *(Әйе, юк)*

Исем + сыйфат конструкциясен сөйләмдә активлаштыру.

*- Бу кызыл тәлинкә.*

“Минем өем” проекты буенча өйрәнелгән боерык фигыльләрне ныгыту *(аша, эч, утыр, ю, уйна, йокла)*, яңа боерык фигыльләрне *(ки, сал)* сөйләмдә аңлап дөрес куллана белергә өйрәтү, активлаштыру.

Алган белемнәрен, сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдә камилләштерү.

**Белем бирү эшчәнлегенең нәтиҗәләре**

Яңа сүзләр хисабына сүз байлыгы бар.

Үзара һәм зурлар белән көндәлек тормышта107 сүз кулланып татар телендә аралаша.

“Уйный-уйный үсәбез” проекты темалары (“Гаилә”, “Ашамлыклар”, “Уенчыклар”, “Саннар” **,** **“**Яшелчәләр”, “Савыт-саба”, “Киемнәр”, “Шәхси гигиена”, “Өй җиһазлары”, “Бәйрәмнәр”) буенча бирелгән лексиканы төрле эшчәнлектә (уен, аралашу, музыка, хезмәт) ишетеп аңлап куллана белә, сөйләм күнекмәләре бар.

Санау күнекмәләре бар, сөйләмдә куллана белә.

Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? соравын аңлап, мөстәкыйль рәвештә сорау куя һәм дөрес җавап бирә.

Раслаучы һәм инкарь итүче сүзләрне аңлый, урынлы куллана.

Исем + сыйфат конструкциясен сөйләмдә дөрес куллана.

Боерык фигыльләрне сөйләмдә аңлап дөрес куллана белә.

Алган белемнәрен, сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдә куллана белә.

### 1.4.3. Татарча сөйләшәбез”, “Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар” проекты, 6-7 яшь

**Лексик минимум** – якынча 60 сүз. “Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар” проекты темалары ( “Гаилә”, “Ашамлыклар”, “Уенчыклар”, “Саннар” **,** **“**Яшелчәләр”, “Савыт-саба”, “Киемнәр”, “Шәхси гигиена”, “Өй җиһазлары”, “Бәйрәмнәр”, “Танышу”, “Тату гаилә”, “Дусларны сыйлыйбыз”, “Кунак килде”, “Кафега барабыз”, “Күңелле уеннар”, “Без циркта”, “Безнең дуслар”, “Чана шуабыз”, “Без биибез”, “Күңелле сәяхәт”, “Мәктәп”, “Без әкият яратабыз”) буенча бирелгән лексиканы төрле эшчәнлектә (танып – белү, уен, аралашу, музыка, хезмәт) ишетеп аңлап куллана белергә өйрәтү, сөйләм күнекмәләрен булдыру.

Яңа сүзләр хисабына баланың сөйләмен баету, тулыландыру: *син кем, хәерле көн, тычкан, бу кем, бу нәрсә, нишли, йоклый, утыра, ашый, эчә, нишлисең, ашыйм, эчәм, уйный, уйныйм, утырам, барам, кая барасың, син нишлисең, сикер-сикерәм, сикерә, йөгерә, төлке, йөгер-йөгерәм, чәк-чәк, өчпочмак, яшь, бүре, керпе, тавык, әтәч, үрдәк, чана, шуа, шуам, бие, бии, биим, ак, кара, җырла-җырлыйм, зур рәхмәт, китап укый, рәсем ясыйм, укыйм, дәфтәр.*

Бу кем? Бу нәрсә? Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? Нишли? Син нишлисең? Кая барасың? соравын аңлап, мөстәкыйль рәвештә сорау куя һәм дөрес җавап бирә белергә өйрәтү.

Алган белемнәрен, сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдә камилләштерү. Монологик сөйләмне үстерү.

**Белем бирү эшчәнлеге нәтиҗәләре**

Яңа сүзләр хисабына сүз байлыгы бар.

Сөйләмне аралашу чарасы буларак файдалана белә.

Диалогик һәм монологик сөйләм күнекмәләре бар.

Үзара һәм өлкәннәр белән 167 сүз кулланып татар телендә актив аралаша.

“Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар” проекты темалары ( “Гаилә”, “Ашамлыклар”, “Уенчыклар”, “Саннар” **,** **“**Яшелчәләр”, “Савыт-саба”, “Киемнәр”, “Шәхси гигиена”, “Өй җиһазлары”, “Бәйрәмнәр”, “Танышу”, “Тату гаилә”, “Дусларны сыйлыйбыз”, “Кунак килде”, “Кафега барабыз”, “Күңелле уеннар”, “Без циркта”, “Безнең дуслар”, “Чана шуабыз”, “Без биибез”, “Күңелле сәяхәт”, “Мәктәп”, “Без әкият яратабыз”) буенча бирелгән лексиканы төрле эшчәнлектә (танып – белү, уен, аралашу, музыка, хезмәт) ишетеп аңлап куллана белә, сөйләм күнекмәләре бар.

Бу кем? Бу нәрсә? Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? Нишли? Син нишлисең? Кая барасың? соравын аңлап, мөстәкыйль рәвештә сорау куя һәм дөрес җавап бирә белә.

Фигыльләрне урынлыкуллана.

Җырлар, шигырьләр белә.

### 1.4.4. Рус төркемнәрендә тәрбияләнүче татар балаларының ана телен үзләштерүгә көтелгән нәтиҗә.

### “Туган телдә сөйләшәбез”, 2-4яшь

Ел дәверендә өйрәнгән сүзләрне, кыска фразаларны аерым, күмәк, тәрбияче ярдәмендә кабатлый белә.

Өлкәннәр кушкан катлаулы булмаган биремнәрне аңлап үти.

Үз исемен дөрес әйтә, исәнләшә, саубуллаша, рәхмәт әйтә белә.

Куелган сорауларны аңлап, сөйләмдә 2-3 сүз белән җавап кайтара белә.

Бер-берсе һәм өлкәннәр белән татар телендә аралаша.

Әйбер исемнәренең мәгънәсен аңлый һәм аларны дөрес әйтә белә.

Син кем?Бу кем? Бу нәрсә?Нәрсә эшли?Нинди? сорауларын аңлап, җавап бирә.

Әйбернең билгесен ачыклау максаты белән куела торган сорауны аңлый һәм сөйләмдә җавап кайтара белә.

Мин, син алмашлыкларын аңлый һәм урынлы куллана.

Кечкенә күләмле шигырьләр, җырлар белә. Татар телендә сөйләшү теләге бар.

### “Туган телдә сөйләшәбез”, 4-5 яшь

Сүз байлыгы бар.

Үзара һәм зурлар белән татар телендә аралаша.

Үзе турында тулы җөмләләр төзеп сөйли белә.Сөйләмендә ягымлы сүзләр,боерыкларны куллана

Санау күнекмәләре бар, сөйләмдә куллана белә.

Нинди? Нишли?Ничә? соравына дөрес җавап бирә.

Иллюстрацияләргә карап әсәрләрнең исемен атый.

Алган белемнәрен, сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдә куллана белә.

### “Туган телдә сөйләшәбез”, 5-6 яшь

Сөйләмне аралашу чарасы буларак файдалана белә.

Диалогик һәм монологик сөйләм күнекмәләре бар.

Үзара һәм өлкәннәр белән татар телендә актив аралаша.

Сүсләрне гомумиләштерә белә.Капма –каршы булган сүзләрне атый.

Җырлар, шигырьләр ,мәкаль,табышмаклар белә.

Алган белемнәрен, сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдә куллана,үзлектән сорау бирә белә.

### “Туган телдә сөйләшәбез”, 6-7 яшь

Сөйләмне аралашу чарасы буларак файдалана белә.

Диалоглы сөйләмдә ягымлы сүзләрне кулланып аралаша белә.Монологик сойләм күнекмәләре бар.

Үзара һәм өлкәннәр белән татар телендә актив аралаша.

Сүсләрне гомумиләштерә белә.Капма –каршы булган сүзләрне атый.

Рәсемгә карап ,аның эчтәлеген сөйли .

Җырлар, шигырьләр ,мәкаль,табышмаклар,санамышлар,әкиятләр белә.

Алган белемнәрен, сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуативкүнегүләрдә куллана,үзлектән сорау бирә белә.

## II НЧЕ БҮЛЕК. Эчтәлек

## 2.1 Балага үсеш юнәлеше буенча белем бирү.

Федераль дәүләт мәгариф стандарты билгеләнгәнчә, мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тәрбия һәм белем бирү эшчәнлеге 5 юнәлештә оештырыла һәм алып барыла: социаль аралашу үсеше, танып-белү үсеше, сөйләм үсеше, нәфис-нәфасәти үсеш, физик үсеш.

**Социаль аралашу үсеш**

– баланың җәмгыятьтә кабул ителгән нормалар һәм кыйммәтләрне, шул исәптән рухи-әхлакый кыйммәтләрне үзләштерүенә;

– яшьтәшләре һәм өлкәннәр белән аралашу һәм хезмәттәшлек итү күнекмәләрен үстерүгә;

– балада мөстәкыйльлек, максатчанлык, үз эш-гамәлләре белән идарә итә белү күнекмәләре булдыруга;

– үзен гаиләнең, мәгариф оешмасындагы балалар һәм өлкәннәр бергәлегенең бер әгъзасы итеп тою хисе һәм үз гаиләсенә, өлкәннәргә һәм яшьтәшләренә ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләүгә;

– балада һәртөрле хезмәткә һәм иҗатка уңай караш булдыруга;

– өйдә, җәмәгать урыннарында, табигатьтә үз иминлеген кайгырта белү нигезләрен формалаштыруга һ.б. юнәлтелгән.

**Танып белү үсеше:**

– баланың кызыксыну өлкәсен киңәйтүне, танып белү омтылышын көчәйтүне;

– күзаллавын, иҗади активлыгын үстерүне;

– балада үзе, башка кешеләр, әйләнә-тирәдәге объектлар, ул объектларның сыйфатлары һәм үзара мөнәсәбәтләре (формасы, төсе, үлчәмнәре, саны, микъдары, бербөтен буларак һәм аерым өлешләре, вакыт һәм пространство һ.б.), баланың туган төбәге һәм Ватаны, милли традицияләр һәм бәйрәмнәр, кешеләрнең уртак яшәү урыны буларак Җир планетасы, илләр һәм халыклар күптөрлелеге һ.б. турында беренче күзаллау формалаштыруны үз эченә ала.

**Сөйләм үсеше дигәндә, баланың:**

– телне культуралылык күрсәткече һәм аралашу чарасы буларак үзләштерүе;

– актив сүзлек запасының даими баетылып торуы;

– грамматик яктан дөрес диалогик һәм монологик бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен үстерү;

– авазларны дөрес ишетү, әйтү күнекмәләрен камилләштерү;

– төрле жанрдагы балалар әдәбияты әсәрләре үрнәкләре белән таныш булуы; ишетеп, аларның кайсы жанрга каравын әйтә белүе;

– грамотага өйрәнүнең алшарты буларак, аваз анализы-синтезының нигезләрен үзләштерүе күзаллана.

**Нәфис-нәфасәти  үсеш балада:**

– нәфис сәнгать (сүз, музыка, рәсем сәнгате) әсәрләрен, табигать дөньясын кыйммәти-мәгънәви яктан бәяли белү һәм аңлауның алшартларын үстерүне;

– әйләнә-тирә дөньяга эстетик караш булдыруны;

– нәфис сәнгать төрләре турында гади күзаллау формалаштыруны;

– музыканы, матур әдәбият әсәрләрен, фольклорны аңлап кабул итү күнекмәләре булдыруны;

– баланың мөстәкыйль иҗади эшчәнлеген гамәлгә ашыруны һ.б. күз алдында тота.

**Физик үсеш балаларның:**

– хәрәкәтләнү, шул исәптән координация һәм сыгылмалылык кебек физик сыйфатларны үстерүгә юнәлтелгән хәрәкәт эшчәнлегендә билгеле күнекмәләргә ия булуын;

– организмның терәк-хәрәкәт системасын дөрес формалаштыруда һәм тигезлекне саклауны ныгытуда булышлык итә торган; кул чукларының төгәл хәрәкәтләр ясау (эре һәм вак предметлар белән эш итү) күнекмәләрен ныгытуга, шулай ук төп хәрәкәтләрне (йөрү, йөгерү, сикерү, як-якка борылуны) организмга зыян килмәслек итеп дөрес башкаруга юнәлтелгән күнегүләр ясауда тәҗрибә туплавын;

– сәламәт яшәү рәвешенең гомуми кагыйдәләрен, нормаларын үзләштерүен;

– кайбер спорт төрләре турында башлангыч күзаллауга ия булуын һ.б. үз эченә ала.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән  министрлыгы тарафыннан Министрлар Кабинеты карары белән кабул ителгән 2010-2015 елларда мәгарифне үстерү Стратегиясе - «Киләчәк» программасы ярдәмендә  мәктәпкәчә тәрбия һәм белем бирү учреждениеләре өчен

Федераль дәүләт мәгариф стандарты таләпләренә җавап бирә алырдай укыту-методик комплектлар булдырылды. УМКга методик әсбаплар, программалар, хрестоматияләр,эш дәфтәрләре,тематик картинкалар,күрсәтмә һәм тарату материаллары, мульти-медиа чаралары керә.Бу комплектларга балаларны татар һәм рус телендә дөрес сөйләшергә өйрәтү,балаларны кызыксындыра алырлык аралашу даирәсе булдыру,сюжетлы уеннар оештыру,гомумән,балаларның актив сөйләмен үстерү максаты куелган. Шөгыльләрдә УМК киң кулланыла, ягъни, без ана, рус телләрендә мультфильмнар карыйбыз, хикәяләр, әкиятләр укыйбыз һәм балалар белән бергә эчтәлеген сөйләп карыйбыз,сюжетлы-рольле, хәрәкәтле һәм түгәрәк уеннар уйныйбыз. Җырлар өйрәнәбез , шигырьләр ятлыйбыз. Картиналар буенча хикәяләр төзергә өйрәнәбез. Сәнгатьле сөйләм, кычкырып уку, хикәя төзеп сөйләү кебек эшләрне башкарганда авазларны дөрес әйтү беренче урынга куела.

Бүгенге көндә балалар бакчасында Татарстан Республикасының ике дәүләт теленә өйрәтү эше системалаштырылган, республиканың Фән һәм мәгариф министрлыгының приказы (№ 463, 29.06.2001) нигезендә. Татар теленә өйрәтү һәм сөйләмне үстерү танып белү, коммуникатив алымнар, матур әдәбият белән таныштыру «Туган телдә сөйләшәбез» укыту-методик комплекты (авторлары З.М.Зарипова, Ф.Хазратова, З.Шәрәфетдинова, И.Хәбибуллина) аша гамәлгә ашырыла. “Туган телдә сөйләшәбез” методик кулланмасы балаларга татар теленең матурлыгын, байлыгын аңларга, үзләрендә күркәм сыйфатлар булдырырга, тел хәзинәсен тирәнтен аңларга, кеше өчен газиз булган туган илгә, туган телебезгә мәхәббәт, әти-әниләргә, өлкәннәргә карата хөрмәт-итәгать тәрбияләргә, үзләрендә хезмәт сөю, тыйнаклык, шәфкатьлелек кебек сыйфатлар булдырырга ярдәм итә.

Рус теле С.М. Гаффарова җитәкчелегендә төзелгән ”Изучаем русский язык” укыту-методик комплекты аша тормышка ашырыла.Бу юнәлештәге эшчәнлек мультимедиа чаралары, «бармак» уеннары, «җанлы» сурәтләр, интерактив уенчыклар, мультфильмнар, сөйләм-хәрәкәтләнү күнегүләре, аваз ияртемнәре кергән уеннар, халык авыз иҗаты әсәрләре, сәхнәләштерү уеннары, иллюстрацияләр куллануны күздә тота.

Мәктәпкә әзерлек төркемнәрендә баланың сүз байлыгын арттыру, бәйләнешле сөйләм теле үсешен тәэмин итү һәм грамотага өйрәтү өчен Резеда Камилевна Шәехованың “Авазларны уйнатып” эш дәфтәрләре зур ярдәм күрсәтә.

Мәктәпкәчә белем бирүнең федераль дәүләт мәгариф стандарты билгеләгәнчә,бакчада тәрбия – белем бирү эшчәнлеге уен формасында алып барылырга тиеш. Балаларның яшь үзенчәлекләренә,кызыксынуларына туры килгән уеннар ярдәмендә алардан аңлы,зыялы, зирәк,җавплы,бер-берсенә һәм олыларга карата мәрхәмәтле,физик яктан чыныккан,җитез,тырыш, көчле ихтыярлы,сәләтле шәхесләр итеп тәрбияләргә мөмкин.

Белем һәм тәрбия бирү процессын дәүдәт стандартларына яраклаштырып алып бару максатыннан, бакчабызда предметлы-үсеш тирәлеге булдырылган.Бер катнаш төркемдә тәрбияләнүче балаларыбыз өчен уен, танып - белү, актив хәрәкәт,сөйләм үсеше ,сәнгать зоналары бар .Әлеге зоналарда балалар тәрбияче белән дә, мөстәкыйль дә шөгылләнәләр.Уен почмагын тулысынча аерым бер темага гына багышлау мәҗбүри түгел.Киресенчә,бала,кирәкле булган предметларны сайлап алып, сюжетны үзе төзесә нәтиҗәлерәк була.Уен почмакларында предметларның төрле зурлыкта һәм күп төрле булуы мөһим.

Тәрбиянең төп асылы - балалар бакчасы белән гаиләнең бердәмлегендә. Тик хезмәттәшлек итеп, ярдәмләшеп эшләгәндә генә,балага бердәм таләпләр куелганда гына уңай нәтиҗәләргә ирешергә була,ягъни,баланың һәрьяклап камил үсешен тәэмин итү өчен мәктәпкәчә белем учреждениеләре алдында гаилә белән үзара хезмәттәшлек итү бурычы тора.Бакчабызда ата-аналар көче белән УМКга кергән мультфильмнар буенча рәсемнәрдән “Минем иң яраткан

мультфильмым”, “Габулла Тукай әкиятләре” буеча һәм кул эшләнмәләреннән төрле күргәзмәләр оештырыла. Төрле бәйрәм иртәләре,семинар-практикумнар,эшлекле уеннар гаилә белән балалар бакчасын берләштерүче үтемле, нәтиҗәле чаралар булып тора.

Балалар мәктәпкә ныклы әзерлек белән килсен өчен балалар бакчасы һәм мәктәп арасында дәвамчанлык булуы мөһим. Бала мәктәпкә укырга кергәнче, мәктәп белән бакча арасында һәр вакыт ныклы элемтә булдырырга тиеш. Мәктәп ягыннан караганда дәвамчанлык-балаларның балалар бакчасында алган беренчел белем һәм күнекмәләргә нигезләнеп һәм шул белемнәрне исәпкә алып барыла.Ә балалар бакчасы ягыннан караганда дәвамчанлык ул-мәктәп таләпләренә ориентлашу, мәктәптә белем алуны дәвам итү өчен кирәк булган белем һәм күнекмәләр формалаштыру. Без дәвамчанлыкны өч юнәлештә алып барабыз:

1) методик эш;

2) балалар белән эш;

3)әти-әниләр белән эш.

Мәктәпкә укырга керүче балалар өчен 1 нче класста ачык дәресләр үткәрелә.Балалар бакчасы балалары мәктәпкә экскурсиягә керәләр: класслар , библиотека һәм музей белән танышалар.

Республика җитәкчелеге балалар бакчасы тәрбиячеләре алдына шундый бурыч куйды: мәктәпкә барганда бала ике дәүләт телендә – татарча да, русча да аралаша белергә тиеш. Татарстан Республикасының ике дәүләт телен үзләштерү фәкать тәрбияче, балалар, ата-аналар берлектә эшләгәндә генә уңай нәтиҗә бирә ала.Уртанчылар төркеменнән башлап, рус телле балалар белергә тиеш актив сүзләр язылган күчерелмә папкалар даими куелып барыла. Ата-аналар һәрдаим танышып торып, гаиләдә дә сүз байлыкларын арттыру өстендә эшләүләре күренә.

Бүгенге көндә мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләрендә белем бирү эшчәнлеген кызыклы,мавыктыргыч итеп оештыру өчен мөмкинлекләр күп. Бары тырышлык һәм үз эшеңне ярата белергә генә кирәк.

## 2.2 Белем бирүдә эш төрләре һәм формалары.

Программа бурычларын үтәүдә эш формаларының, практик гамәлиалымнарның, чараларның әһәмияте зур. Төп эш төрләре булып түбәндәгеләр тора:

1. Предметлар белән эш: тасвирлау, уенчык белән диалог төзү, уен һәмәкиятләрдә катнашу.
2. Рәсемнәр белән эш: тасвирлау, үстерешле диалог.
3. Сюжетлы-рольле уеннар;
4. Әйлән-бәйлән, җырлы-биюле уеннар өйрәнү (аудиоязмага таянып).
5. Театральләштерү, сәхнәләштерү (бармак театры, битлекләр, костюмнар,театр күрсәтү (әти-әниләргә, башка төркем балаларына).
6. Хәрәкәтле уеннар: туп белән уеннар, “Командир” уены, әйлән-бәйлән уен,зарядка уеннары.
7. Иҗади һәм ситуатив уеннар: рольле уеннар, интервью, ситуатив күнегүләр.
8. Ситуатив, логик күнегүләрне ишетеп, аңлап эшләү.
9. Үстерелешле диалоглар (зурлар һәм яшьтәшләре белән үзара аралашу).
10. Аудиоязмалар тыңлау, кушылып әйтү, җырлау, кабатлау, ишеткән сүзнерәсемдә табып күрсәтү.
11. Анимацион сюжетлар, мультфильмнар карау.
12. Интерактив уеннар.

## 2.3 Комплекслы-тематик план

### 2.3.1. “Татарча сөйләшәбез”, “Минем өем проекты”, 4-5 яшь

| № | Проект темалары | Эшчәнлек саны |
|---|---|---|

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Кабинеттагы уенчыклар белән таныштыру | 1 |
| 2. | Уеннар уйнау | 1 |
| 3. | Әкият иленә сәяхәт | 1 |
| 4. | Минем гаиләм | 2 |
| 5. | “Көз белән балалар”җыры | 2 |
| 6. | Малай, кыз | 2 |
| 7. | Минем туганнарым | 1 |
| 8. | Минем гаиләм | 1 |
| 9. | Шалкан әкияте | 2 |
| 10. | Әйдәгез, танышыйк | 3 |
| 11. | Әйдәгез, дуслашыйк | 1 |
| 12. | Тату гаилә | 1 |
| 13. | Качышлы уйныйбыз | 1 |
| 14. | Минем дусларым | 2 |
| 15. | Мультфильм карау | 2 |
| 16. | Әйе, юк | 2 |
| 17. | Кунак килгән | 4 |
| 18. | Әйдәгез, уйныйбыз | 2 |
| 19. | Безнең кунаклар | 2 |
| 20. | Әби күчтәнәче | 2 |
| 21. | Бабай күчтәнәче | 2 |
| 22. | Әкият илендә тапшыруы | 3 |
| 23. | Азат кунак чакыра | 2 |
| 24. | Сөт, чәй | 1 |
| 25. | Дустыңны сыйла | 3 |
| 26. | Рәхмәт әйт | 2 |
| 27. | Песине сыйла | 1 |
| 28. | Кунак сыйлау | 1 |
| 29. | Кунакны ашат | 1 |
| 30. | Чәй табынында | 1 |
| 31. | Уенчыклар | 3 |
| 32. | Зур – кечкенә | 1 |
| 33. | Күңел ачу кичәсе “Туган көн” | 1 |
| 34. | Курчак кунакка килгән | 3 |
| 35. | Уенчыклар кибете | 6 |
| 36. | Паркка сәяхәт | 2 |
| 37. | Яңа уенчыклар | 2 |
| 38. | Уйныйбыз | 2 |
| 39. | Без уйнарга яратабыз | 1 |
| 40. | Алсуның туган көне | 1 |
| 41. | Мияуга бүләк | 1 |
| 42. | Уенчыклар үпкәләгән | 1 |
| 43. | Бүләкләр | 4 |
| 44. | Уйна | 4 |
| 45. | Күңелле уеннар | 4 |
| 46. | Уенчыклар юабыз | 5 |
| 47. | Уенчык ю! | 2 |
| 48. | Акбай белән Мияу маҗаралары | 1 |
| 49. | Саннар | 1 |
| 50. | Уйныйбыз да, саныйбыз | 1 |
| 51. | Ничә уенчык? | 2 |

| | | |
|---|---|---|
| 52. | Уйный-уйный саныйбыз | 2 |
| 53. | Кунак чакырабыз | 2 |
| 54. | Бергәләп уйныйбыз | 2 |
| 55. | Күңелле ял итәбез | 2 |
| 56. | Без татарча сөйләшәбез | 2 |
| 57. | Бу өйдә кем яши? | 1 |
| 58. | Театр уйныйбыз | 2 |
| 59. | Акбай, Мияу кунак чакыра | 1 |
| | | **114 сәгать** |

## 2.3.2. “Татарча сөйләшәбез”, “Уйный-уйный үсәбез”, 5-6 яшь

| **АКТИВ СҮЗЛӘР** | **СӨЙЛӘМ ҮРНӘГЕ** | **АУДИОЯЗМА ЭШ ДӘФТӘРЕ АНИМАЦИОН СЮЖЕТ** |
|---|---|---|
| **ГАИЛӘ – 18 СӘГАТЬ (1-18)** | | |
| эти | -Бу кем? | Аудиоязма №1-23 |
| эни | -Әти (әни, бабай, әби, кыз, малай). | |
| | | Дәфтәрдә эш №1-4 |
| малай | -Кем юк? | |
| кыз | -Әти (әни, бабай, әби, малай, кыз). | Сюжетлар: |
| | | 1. “Әйдәгез, дуслашыйк” |
| мин | -Исәнмесез. | 2. “Качышлы уйныйбыз” |
| исәнмесез | -Син кем? | 3. “Шалкан” |
| сау | -Мин Коля (Оля). | |
| булыгыз | -Мин малай. | |
| | -Сау булыгыз! | |
| | | |
| исәнме | -Исәнме, әни (эти, бабай, әби, кыз, малай, Мияу, Акбай). | |
| | -Сау бул, әни (эти, бабай, әби, кыз, малай). | |
| | | |
| эт | -Кем анда? | |
| песи | -Мин песи. Мин Мияу. | |
| | -Кил монда. | |
| | -Мин эт. Мин Акбай. | |
| | -Кил монда. | |
| | | |
| әйе | -Син Коля? | |
| юк | -Әйе, Коля. | |
| сау бул | -Син малай (кыз)? | |
| | -Әйе (юк). | |
| | | |
| әби | -Әти? (әни, бабай, әби, кыз, малай). | |
| бабай | -Әйе. | |
| | -Әни? (эти, бабай, әби, кыз, малай). | |
| | -Юк. | |

| | | |
|---|---|---|
| | -Малай? | |
| | -Юк, кыз. | |
| | -Кыз? | |
| | -Әйе, кыз. | |
| әйбәт | -Хәлләр ничек? | |
| | -Әйбәт. | |
| **АШАМЛЫКЛАР – 12 СӘГАТЬ (19-30)** | | |
| ипи | -Мә, ипи (алма, сөт, чәй). | Аудиоязма №24-39 |
| | -Рәхмәт, әби. | |
| алма | | Дәфтәрдә эш №5-10 |
| сөт | -Коля, мә ипи (алма, сөт, чәй). | Сюжетлар: |
| чәй | -Рәхмәт. | 1.“Тәмле” кибетендә” |
| | | 2. “Азат кунак чакыра” |
| мә | | |
| рәхмәт | | |
| тәмле | -Мияу, кил монда. Утыр. (Акбай, Коля, Оля) | |
| кил монда | | |
| утыр | -Оля, кил монда. Мә ипи (алма, сөт, чәй). Ипи (алма, сөт, чәй) тәмле (ме)? | |
| | -Ипи (алма, сөт, чәй) тәмле. Рәхмәт. | |
| | -Мә, тәмле алма (ипи). | |
| аша | -Мә, ипи (алма) аша. | |
| эч | -Мә, сөт (чәй) эч. | |
| **УЕНЧЫКЛАР – 18 СӘГАТЬ (31-48)** | | |
| бир | - Бу нәрсә? | Аудиоязма №40-53 |
| туп | - Туп (курчак, куян, аю). | |
| | | Дәфтәрдә эш №11-13 |
| зур | -Курчак (туп, куян, аю) бир. | |
| кечкенә | -Мә, курчак (туп, куян, аю). | Сюжетлар: |
| | | 1. “Паркка сәяхәт” |
| матур | -Бу нәрсә? | 2. “Уенчыклар үпкәләгән” |
| курчак | -Аю (курчак, куян, туп). | 3. “Күңелле уеннар” |
| | -Аю (курчак, куян, туп) нинди? | 4. “Акбай һәм Мияу маҗаралары” |
| куян | -Аю (курчак, куян, туп) зур (матур, кечкенә, әйбәт). | |
| аю | | |
| | - Аю (курчак, куян, туп) нинди? | |
| | - Аю (курчак, куян, туп) зур (кечкенә, матур, әйбәт). | |
| | -Аю (курчак, куян, туп)? | |
| | -Әйе. | |

| | | |
|---|---|---|
| хәлләр<br>ничек?<br>уйна<br>пычрак<br>чиста<br>ю | -Курчак (аю, куян, туп)?<br>-Юк.<br><br>-Бу нәрсә?<br>-Аю (курчак, куян, туп).<br>-Мә, аю (курчак, куян, туп). Уйна.<br><br>-Коля, кил монда. Уйна.<br>-Оля, кил монда. Уйна.<br><br>- Аю (курчак, куян, туп) бир.<br>- Аю (курчак, куян, туп) нинди?<br>- Аю (курчак, куян, туп) зур.<br>- Аю (курчак, куян, туп) кечкенә.<br><br>- Мә, зур аю (курчак, куян, туп).<br>- Мә, кечкенә аю (курчак, куян, туп).<br>-Аю (курчак, куян), кил монда. Аша (утыр, эч, уйна).<br><br>-Коля (Оля), аю (курчак, куян, туп) ю.<br><br>-Туп (курчак, куян, аю) нинди?<br>-Туп (курчак, куян, аю) пычрак (чиста).<br>-Туп ю.<br>- Туп чиста?<br>- Юк, туп пычрак.<br>(Әйе, туп чиста).<br>Ю, ю, ю – туп (курчак, аю, куян) ю. | |
| **САННАР - 6 СӘГАТЬ (49-54)** | | |
| бер<br>ике<br>өч<br>дүрт<br>биш | -Ничә?<br>-Бер (ике, өч, дүрт, биш) алма.<br><br>-Ничә малай?<br>-Бер (ике, өч, дүрт, биш) малай.<br>-Ничә кыз?<br>-Бер (ике, өч, дүрт, биш) кыз.<br><br>-Өч?<br>-Юк.<br>-Ике?<br>-Әйе.<br><br>-Ничә аю (туп, курчак, куян)?<br>-Бер (ике, өч, дүрт, биш) аю. | Аудиоязма №54-60<br>Дәфтәрдә эш №14<br>Сюжет:<br>1.“Уйный-уйный саныйбыз” |
| **КАБАТЛАУ - 6 СӘГАТЬ (55-60)** | | |

| | | |
|---|---|---|
| | | Аудиоязма №61-64<br>Дәфтәрдә эш №16-17<br>Сюжет:<br>1. “Күңелле ял итәбез” |

| № | **Проект темалары** | **Эшчәнлек саны** |
|---|---|---|
| 1. | Үткәннәрне кабатлау | 8 |
| 2. | Минем өем | 2 |
| 3. | Кем юк? | 1 |
| 4. | Кишер үстерәбез | 1 |
| 5. | Үткән теманы ныгыту | 6 |
| 6. | Шалкан әкияте | 1 |
| 7. | Куян күчтәнәче | 1 |
| 8. | Кабатлау | 12 |
| 9. | Мультфильм “Баллы кишер” | 1 |
| 10. | Серле кәрзин | 2 |
| 11. | Сыйлыйбыз | 1 |
| 12. | Бар матур бакча | 2 |
| 13. | Ныгыту | 1 |
| 14. | Серле янчык | 1 |
| 15. | Без хезмәт яратабыз | 1 |
| 16. | Яшелчәләр кибете | 2 |
| 17. | Уйный-уйный эшлибез | 1 |
| 18. | Үткән теманы кабатлау | 1 |
| 19. | Төсләр дөньясы | 3 |
| 20. | Узганнарны кабатлау | 1 |
| 21. | Юл маҗаралары | 2 |
| 22. | Яшелчә салаты | 3 |
| 23. | Яшелчә | 3 |
| 24. | Кем эшләми, шул ашамый | 2 |
| 25. | Уйныйбыз да, җырлыйбыз да | 1 |
| 26. | Уңыш бәйрәме | 1 |
| 27. | Ашамлыклар | 1 |
| 28. | Ашханә | 2 |
| 29. | Аш бүлмәсе | 1 |
| 30. | “Аю кунакка килгән” | 1 |
| 31. | Кибеттә | 1 |
| 32. | “Кем нәрсә ярата?” | 3 |
| 33. | Туган көн | 2 |
| 34. | Курчак, Алиягә булыш! | 1 |
| 35. | Өч аю | 1 |
| 36. | Чәй табыны әзерлибез | 1 |
| 37. | Төсле чынаяклар | 1 |
| 38. | Чисталыкта –матурлык | 3 |
| 39. | Туган көнгә яңа киемнәр | 1 |
| 40. | Киемнәр кибетендә | 1 |
| 41. | Курчакны киендер | 2 |
| 42. | Без киенәбез | 1 |
| 43. | Киенергә ярдәм ит | 3 |
| 44. | Алия йокларга җыена | 2 |

| | | |
|---|---|---|
| 45. | Шаян уенчыклар | 1 |
| 46. | Хәерле көн | 2 |
| 47. | Курчак белән уйныйбыз | 2 |
| 48. | Ни өчен киемнәр югалган? | 2 |
| 49. | Өстәл театры “Өч аю” | 1 |
| 50. | Җиһазлар кибете | 1 |
| 51. | Маша һәм өч аю | 1 |
| 52. | Уенчыклар иленә сәяхәт | 1 |
| 53. | Кибет уены | 1 |
| 54. | Курчакның туган көне | 1 |
| 55. | Туган көн | 2 |
| 56. | Уйнарга яратабыз | 2 |
| 57. | Син нәрсә яратасың? | 1 |
| 58. | Уйный-уйный үсәбез | 1 |
| 59. | Нәрсә бар? | 1 |
| 60. | Бар, юк | 1 |
| 61. | Сабантуйга әзерләнәбез | 1 |
| 62. | Күңелле Сабантуй | 1 |
| 63. | Сабантуй бәйрәме | 1 |
| | | **114 сәгать** |

| **АКТИВ СҮЗЛӘР** | **СӨЙЛӘМ ҮРНӘГЕ** | **АУДИОЯЗМА<br>ЭШ ДӘФТӘРЕ<br>АНИМАЦИОН СЮЖЕТ** |
|---|---|---|
| **КАБАТЛАУ – 3 СӘГАТЬ (1-3)** | | |
| | “Минем өем” проекты буенча | Аудиоязма №1<br>Дәфтәрдә эш №1<br>Сюжет:<br>1. “Шалкан” |
| **ЯШЕЛЧӘЛӘР – 21 СӘГАТЬ (4-24)** | | |
| кишер<br><br><br><br>баллы | -Бу нәрсә?<br>-Кишер.<br>-Мә, кишер.<br>-Нинди кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)?<br>-Зур (кечкенә) кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br>-Мә, зур (кечкенә) кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br>-Рәхмәт.<br><br>-Зур кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br>-Кечкенә кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br>-Чиста кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br>-Пычрак кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br><br>-Кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр) нинди?<br>-Кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр) тәмле, зур (кечкенә), матур, чиста (пычрак) | Аудиоязма №2-24<br><br>Дәфтәрдә эш №2-6<br>Сюжетлар:<br>1.“Баллы кишер”<br>2. “Уйный-уйный эшлибез”<br>3. “Юл маҗаралары”<br>4. “Кем эшләми, шул ашамый” |

| | | |
|---|---|---|
| ничә<br>суган<br>бәрәңге<br>кыяр<br>кәбестә<br>нинди<br>алты<br>җиде<br>сигез<br>тугыз<br>ун<br>кызыл<br>сары<br>яшел<br>нәрсә<br>кирәк?<br>юа | Кишер баллы.<br>Алма баллы.<br>-Мә кишер(алма), аша. Баллы?<br>-Әйе, баллы. Рәхмәт.<br><br>-Ничә кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)? Сана.<br>-Ике (1-10) кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br>-Оля, кил монда. Мә, ике (1-10) кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br>-Ике (1-10) кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br><br>-Оля, кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә, кишер) бир.<br>-Мә, кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә,кишер).<br>-Рәхмәт.<br><br>-Коля, (1-10) кәбестә (суган, бәрәңге, кишер, кыяр) бир.<br>-Мә, (1-10) кәбестә (суган, бәрәңге, кишер, кыяр).<br>-Сау бул, Коля.<br><br>-Ничә кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә, кишер)?<br>-Бер (1-10) кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә, кишер).<br>-Кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә, кишер) пычрак.<br><br>-Бу туп.<br>-Туп (алма) нинди?<br>-Туп (алма) сары (кызыл, яшел)<br><br>-Нинди туп (алма) юк?<br>-Кызыл (сары, яшел) туп (алма) юк.<br><br>-Кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр) кирәк?<br>-Кирәк.<br><br>-Коля, нәрсә кирәк?<br>-Кыяр (суган, кишер, бәрәңге, кәбестә) кирәк.<br>-Нинди кыяр?<br>-Яшел (тәмле, чиста) кыяр.<br><br>-Кыяр (суган, кишер, бәрәңге, кәбестә) пычрак.<br>-Мә, кыяр (суган, кишер, бәрәңге, кәбестә) ю.<br>-Оля кыяр ( суган, кишер, бәрәңге, кәбестә) юа. | |
| **АШАМЛЫКЛАР – 6 СӘГАТЬ (25-30)** | | |
| аш | тәмле аш (ботка, сөт, ипи, чәй) | Аудиоязма №25-29 |

| | | |
|---|---|---|
| ботка | -Нәрсә кирәк?<br>-Аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге) кирәк.<br>-Нинди аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге)?<br>-Тәмле аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге).<br>-Мә, аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге) аша (эч).<br>-Рәхмәт. Аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге) тәмле. | Дәфтәрдә эш №7, 8<br><br>Сюжет:<br>1.“Аш бүлмәсе” |
| **САВЫТ-САБА - 6 СӘГАТЬ (31-36)** | | |
| кашык<br>тәлинкә<br><br>чынаяк<br><br>зәңгәр | -Кашык (тәлинкә, чынаяк) бир.<br>-Нинди кашык (тәлинкә, чынаяк)?<br>-Зур (кечкенә, сары, яшел, кызыл, зәңгәр).<br>-Ничә кашык (тәлинкә, чынаяк)?<br>-(1-10 га) кашык (тәлинкә, чынаяк).<br>-Мә, (1-10) кашык(тәлинкә, чынаяк).<br>-Мә, кызыл (сары, яшел, зәңгәр). чынаяк (тәлинкә, чынаяк). | Аудиоязма №30-37<br>Дәфтәрдә эш №9, 10<br>Сюжет:<br>1. “Өч аю”<br>2. “Чисталыкта - матурлык” |
| **КИЕМНӘР - 6 СӘГАТЬ (37-42)** | | |
| күлмәк<br><br>чалбар<br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br>ки<br><br><br><br>сал<br><br>йокла | яшел (кызыл, сары, зәңгәр) күлмәк (чалбар).<br><br>чиста күлмәк (чалбар).<br>матур күлмәк (чалбар).<br><br>күлмәк (чалбар) юк.<br><br>-Оля, күлмәк (чалбар) бир.<br>-Нинди күлмәк (чалбар)?<br>-Сары (кызыл, яшел, зәңгәр) күлмәк (чалбар).<br>-Ничә күлмәк (чалбар)?<br>-Бер (1-10) күлмәк (чалбар).<br><br>-Курчак, чалбар (күлмәк) ки (сал).<br><br>-Оля, чалбар (күлмәк) бир.<br>-Мә, чалбар (күлмәк).<br>-Рәхмәт. Курчак, мә, чалбар (күлмәк) ки (сал).<br><br>-Курчак, йокла. | Аудиоязма №38-43<br><br>Дәфтәрдә эш №11, 12<br><br>Сюжет:<br>1.“Киемнәр кибетендә”<br>2.“Шаян уенчыклар” |
| **ШӘХСИ ГИГИЕНА – 3 СӘГАТЬ (43-45)** | | |
| бит<br>кул | -Хәерле көн.<br>-Мә су, бит (кул) ю. | Аудиоязма № 43, 44-48 |

| | | |
|---|---|---|
| 8.00-8.15<br><br>8.15-9.00<br><br>9.00-9.30<br>9.30-10.00<br>10.05-10.30<br><br>10.30-11.30<br>11.30-11.55<br><br>11.55-12.30<br>12.30-13.00<br>13.00-14.00<br>14.00-14.30<br>14.30-15.00<br><br>15.00-15.20<br>15.20-15.50<br><br>15.50-16.00 | Игровая деятельность по родному языку во второй младшей<br>группе(Р/м)<br>Индивидуальная работа в средней группе показателями по<br>диагностике ниже среднего<br>Татарский язык в подготовительной (1)группе<br>Родной язык в подготовительной (1)группе<br>Игровая деятельность по родному языку и татарскому языку в<br>старшей (1) группе(Р/м)<br>Индивидуальная работа в старшей (1) группе<br>Игровая деятельность по родному языку и татарскому языку в<br>старшей группе (Р/м)<br>Индивидуальная работа в группах<br>Обед<br>Работа с документами<br>Работа в родительском уголке<br>Работа с тетрадями по коррекционной (показатели ниже<br>среднего) работе<br>Подготовка демонстрационного и раздаточного материала<br>Родной язык и татарский язык в подготовительной<br>логопедической группе<br>Индивидуальная работа в подготовительной логопедической<br>группе | Групповая комната<br><br>Кабинет тат языка<br><br>Кабинет тат.языка<br>Кабинет тат.языка<br>Групповая комната<br><br>Кабинет тат языка<br>Групповая комната<br><br>Групповая комната<br><br>Кабинет тат языка<br>Групповая комната<br>Кабинет тат языка<br><br>Кабинет тат языка<br>Групповая комната<br><br>Групповая комната |
| **8.00 – 15.00** | **Четверг** | |
| 8.00-8.20<br><br>8.20-9.00<br>9.00-9.20<br>9.20-9.40<br>9.40-10.10 | Игровая деятельность по родному языку в средней группе (Р/м)<br>Подготовка демонстрационного и раздаточного материала<br>Индивидуальная работа в средней группе<br>Подготовка демонстрационного и раздаточного материала<br>Татарский язык в подготовительной группе<br>Родной язык в подготовительной группе | Групповая комната<br><br>Кабинет тат языка<br>Кабинет тат языка<br>Кабинет тат языка<br>Кабинет тат.языка |

| | | |
|---|---|---|
| 10.10-10.40<br>10.40-11.30<br>11.30-11.55<br>11.55-12.25<br>12.30-13.00<br>13.00-14.20<br>14.20-15.00 | Работа с тетрадями по коррекционной работе<br>Игровая деятельность по родному и татарскому языку в старшей (1)группе(Р/м)<br>Индивидуальная работа в группах<br>Обед<br>Работа с документами(планами)<br>Работа в родительском уголке | Кабинет тат языка<br>Кабинет тат языка<br>Групповая комната<br>Групповая комната<br><br>Кабинет тат языка<br>Групповая комната |
| **8.00 – 14.00** | **Пятница** | |
| 8.00-8.15<br><br>8.15-8.30<br>8.30-9.00<br>9.00-9.40<br>9.40-10.10<br><br>10.10-10.20<br><br>10.20-10.45<br><br>10.45-11.20<br><br>11.20-11.50<br><br>11.50-12.30<br>12.30-13.00<br>13.00-14.00 | Игровая деятельность по родному языку во второй младшей группе (Р/м)<br>Индивидуальная работа в подготовительной группе<br>Подготовка информации в уголках для родителей<br>Подготовка демонстрационного и раздаточного материала<br>Родной и татарский язык в подготовительной логопедической группе<br>Индивидуальная работа в подготовительной логопедической группе<br>Игровая деятельность по родному языку и татарскому языку в старшей группе(Р/м)<br>Работа с тетрадями по коррекционной (показатели ниже среднего) работе<br>Игровая деятельность по родному языку и татарскому языку в подготовительной (1) группе(Р/м)<br>Работа в родительском уголке<br>Обед<br>Работа с документами (планами) | Групповая комната<br><br>Групповая комната<br>Кабинет тат языка<br>Кабинет тат.языка<br>Групповая комната<br><br>Групповая комната<br><br>Групповая комната<br><br>Кабинет тат языка<br><br>Групповая комната<br><br>Групповая комната<br><br>Кабинет тат языка |

## Белем бирү эшчәнлек челтәре

| № | Төркемнәр | Дүшәмбе | Сишәмбе | Чәршәмбе | Пәнҗешәмбе | Җомга |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | **2 кечкенәләр** | Ана теле 8.00-8.15 (Р/м) | | Ана теле 8.00-8.15 (Р/м) | | Ана теле 8.00-8.15 (Р/м) |
| 2. | **Уртанчылар** | Тат.теле/Ана теле 10.00-10.20 (Р/м) | Тат.теле/Ана теле 8.00-8.20 (Р/м) | | Тат.теле/Ана теле 8.00-8.20 (Р/м) | |
| 3. | **Зурлар** | | Тат.теле 9.00-9.25 Ана теле 9.25-9.50 (ОД) | Тат.теле/Ана теле 11.30-11.55 (Р/м) | | Тат.теле/Ана теле 10.20-10.45 (Р/м) |
| 4. | **Зурлар(1)** | Тат.теле 9.00-9.25 Ана теле 9.25-9.50 (ОД) | | Тат.теле/Ана теле 10.05-10.30 (Р/м) | Тат.теле/Ана теле 11.30-11.55 (Р/м) | |
| 5. | **Мәктәпкә әзерлек төркеме** | Тат.теле/Ана теле 11.30-12.00 (Р/м) | Тат.теле/Ана теле 15.20-15.50 (ОД) | | Тат.теле 9.40-10.10 Ана теле 10.10-10.40 (ОД) | |
| 6. | **Мәктәпкә әзерлек төркеме(1)** | | Тат.теле/Ана теле 10.00-10.30 (ОД) | Тат.теле 9.00-9.30 Ана теле 9.30-10.00 (ОД) | | Тат.теле/Ана теле 11.20-11.50 (Р/м) |
| 7. | **Мәктәпкә әзерлек төркеме (логопедия)** | | Тат.теле/Ана теле 11.20-11.50 (Р/м) | Тат.теле/Ана теле 15.20-15.50 (ОД) | | Тат.теле/Ана теле 9.40-10.10 (ОД) |

## 3.6 Кулланылган әдәбият

1.Мәктәпкәчә мәгарифнең Федераль дәүләт белем стандарты (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2013елның 17 октябрендә 1155 нче номерлы боерык нигезендә расланган).

2.Татарстан Республикасының “Татарстан Республикасында Татарстан Республикасының дәүләт телләре һәм башка телләр турында” Законы.

3.Зарипова З.М., Кидрячева Р.Г. Балалар бакчасында рус балаларына татар теле өйрәтү программасы. «Идел-Пресс», 2013.

4.Зарипова З.М., Кидрячева Р.Г. “Татарча сөйләшәбез”. 4-5 яшьлек балаларны татар теленә өйрәтү буенча методик ярдәмлек, «Хәтер», 2011

5.Зарипова З.М., Кидрячева Р.Г. “Татарча сөйләшәбез”. 5-6 яшьлек балаларны татар теленә өйрәтү буенча методик ярдәмлек, «Хәтер», 2012

6.Зарипова З.М., Кидрячева Р.Г. “Татарча сөйләшәбез”. 6-7 яшьлек балаларны татар теленә өйрәтү буенча методик ярдәмлек, «Татарстан китап нәшрияты», 2012.

7.Закирова К.В., Муртазина Л.Р. “Әй, уйныйбыз, уйныйбыз”.- Казан, 2013.

8.Зарипова З.М., Исаева Р.С. “Үстерешле уен”.- Казан, 2013.

9.К. В. Закирова К.В., Муртазина Л.Р. “Балачак – уйнап - көлеп үсәр чак”.- Казан, 2013.

# КУШЫМТА.
## ДИАГНОСТИКА
### “Туган телдә сөйләшәбез”, 2-3 яшь

| № | Баланың исеме, фамилиясе | Сүз байлыгы | Сөйләмнең грамматик ягы | | Уеннарда катнашу | Аваз культурасы | Бәйләнешле сөйләм | | Баллар | Дәрәҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Бу кем? Бу нәрсә? | Бирем үтәү | Нинди? | | Ул ничек кычкыра? | Үзең турында сөйләү (Син кем?) | Рәсем буенча әңгәмә (Сорау-җавап) | | |
| | | | | | | | | | | |

ДИАГНОСТИК БИРЕМНӘР (ел башына)

**1. БАЛАЛАРНЫҢ СҮЗ БАЙЛЫГЫ**

**1. «Бу нәрсә?» дидактик уены**

Материал: уенчыклар, җиләк-җимеш, яшелчәләр сурәтләнгән предметлы рәсемнәр.

Диагностик биремнең эчтәлеге:

Тәрбияче балага уенчык (машина, курчак, туп) рәсемнәре күрсәтә һәм аларның нәрсә икәнлеген әйтергә куша. Аннары предметларның өлешләрен күр сәтергә тәкъдим итә. Мәсәлән: «Машинаның кабинасын күрсәт. Кузовын күрсәт. Тәгәрмәчләрен күрсәт».

Тәрбияче балага җиләк-җимешләр (алма, груша, слива) рәсемнәре күрсәтә һәм аларның нәрсә икәнлеген әйтергә куша: «Бу нәрсә?» Балалардан җиләк-җимешләрнең төсләрен (кызыл, яшел, сары) сорый.

Тәрбияче балага яшелчәләр (кишер, кыяр, помидор) рәсемнәре күрсәтә һәм аларның нәрсә икәнлеген әйтергә куша: «Бу нәрсә?» Аннары яшелчәләрнең төсләрен сорый.

**2. «Син кем?» дидактик күнегүе**

Диагностик биремнең эчтәлеге

Тәрбияче баланы үзе янына чакыра, аңа сораулар бирә: «Синең исемең ничек?» «Ә минем исемем ничек?» «Ул —кыз, ә син кем?» «Башыңны күрсәт әле. Кая синең борының (күзләрең, колакларың, кулларың, аякларың)?» Рәсем буенча гаилә әгъзаларын әйтү (Бабай, әби, әти, әни, малай, кыз).

Бәяләү критерийлары

Бала, предметларның исемен атаганда, төсләрен билгеләгәндә, хаталар җибәрә. Тәрбияченең сорауларына җавапбирә алмый — 1 балл;

бала предметларның исемен дөрес атый, төсләрен билгеләгәндә, хаталар җибәрә. Тәрбияченең сорауларына өстәмә сораулар ярдәмендә генә җавап бирә — 2 балл;

бала предметларның исемен дөрес атый, төсләрне дөрес билгели. Тәрбияченең сорауларына теләп, ышанычлы итеп җавап бирә — 3 балл.

**2. СӨЙЛӘМНЕҢ ГРАММАТИК ЯГЫ**

**1. «Кем нәрсә эшли?» дидактик уены**

Материал: табибә, шофёр, сатучы сурәтләнгән сюжетлы рәсемнәр.

Диагностик биремнең эчтәлеге

Тәрбияче балага табибә төшерелгән сюжетлы рәсем күрсәтә һәм сораулар бирә: «Бу кем?» (Табибә.) «Ул нәрсә эшли?» (Тыңлый.) «Ул кемне дәвалый?» (Малайны дәвалый.)

Тәрбияче балага шофёр төшерелгән сюжетлы рәсем күрсәтә һәм сораулар бирә: «Бу кем?» (Шофёр.) «Шофёр кайда утыра?» (Кабинада утыра.) «Ул нишли?» (Машина йөртә.)

Тәрбияче балага сатучы төшерелгән сюжетлы рәсем күрсәтә һәм сораулар бирә: «Бу кем?» (Сатучы.) «Сатучы кайда эшли?» (Кибеттә.) «Ул нәрсә эшли?» (Ул әйбер сата.)

Бәяләү критерийлары

Бала биремнәрне үти алмый. Тәрбиячелең сорауларына җавап бирә алмый. Тәрбияче актив ярдәм күрсәткәндә дә, хаталар ясый — 1 балл;

бала биремнәрне үтәргә тырыша, тәрбиячелең сорауларына бер сүз белән генә җавап бирә — 2 балл;

бала биремнәрне дөрес үти. Тәрбиячелең сорауларына җавап биргәндә, исем белән фигыльне, алмашлык белән фигыльне яраклаштыра ала. Тәрбиячелең сорауларына теләп, ышанычлы итеп җавап бирә — 3 балл.

**3. АВАЗ КУЛЬТУРАСЫ**

**1. «Бу нәрсә? Ул ничек кычкыра?» дидактик уены**

Материал: песи, эт, әтәч, сыер, күгәрчен, чыпчык рә семнәре.

Диагностик биремнең эчтәлеге

Тәрбияче балага песи (эт, әтәч, сыер, күгәрчен, чыпчык) рәсемнәре күрсәтә һәм сораулар бирә: «Бу нәрсә?» (Эт.) «Эт ничек өрә?» («Һау-һау!») «Бу нәрсә?» (Песи.) «Песи ничек кычкыра?» («Мияу-мияу!») «Бу нәрсә?» (Әтәч.) «Әтәч ничек кычкыра?» («Кикрикү-үк!») «Бу нәрсә?» (Сыер.) «Сыер ничек мөгри?» («Му-у!») «Бу нәрсә?» («Күгәрчен.) «Күгәрчен ничек гөрли?» («Гөр-гөр!») «Бу нәрсә?» (Чыпчык.) «Чыпчык ничек чыркылдый?» («Чырык-чырык!»)

Бәяләү критерийлары

Бала 1—2 биремне генә үти ала — 1 балл;

бала биремнәрне тәрбияче ярдәме белән башкара, аның артыннан кабатлый — 2 балл;

бала биремнәрне теләп башкара, аваз иялтемнәрен дөрес һәм ачык итеп әйтә — 3 балл.

**4. БӘЙЛӘНЕШЛЕ СӨЙЛӘМ**

**1. Сюжетлы рәсем буенча әңгәмә**

Материал: уйнаучы балалар сурәтләнгән сюжетлы рәсем.

Диагностик биремнең эчтәлеге

Тәрбияче балаларның игътибарын рәсемгә юнәлтә һәм сораулар бирә: «Карагыз әле, Йомшаккай бик матур бер рәсем ясаган. Бу рәсемдә кем ясалган? Балалар нәрсә эшлиләр? Рәсем сиңа ошыймы?»

Бәяләү критерийлары

Бала сорауларга ишарәләр яки бер сүз белән генә җавап бирә — 1 балл;

бала, җавап биргәндә, 2—3 сүздән торган гади җөмләләргә өстенлек бирә — 2 балл;

бала гади (кем? нәрсә?) һәм катлаулы (кемгә? нинди? кайчан? кайда? кая?) сорауларга җавап бирә. Үз инициативасы белән яки тәрбияче кушуы буенча, рәсемдә сурәтләнгәнне сөйли ала — 3 балл.

10—12 балл: югары дәрәҗә

6—9 балл: уртача дәрәҗә

3—5 балл: түбән дәрәҗә

**ДИАГНОСТИК БИРЕМНӘР (ел азагы)**

**1. БАЛАНЫҢ СҮЗ БАЙЛЫГЫ**

**1. «Бу нәрсә?» дидактик уены**

Материал: савыт-саба, йорт җиһазлары, йорт хайваннары, кыргый хайваннар, киемнәр сурәтләнгән рәсемнәр.

Диагностик биремнең эчтәлеге

Тәрбияче балага савыт-саба (тәлинкә, чынаяк, чәй тәлинкәсе, табак) сурәтләнгән рәсемнәр күрсәтә һәм андагы предметларны атарга куша: «Бу нәрсә?» «Бу предметлар бер сүз белән ничек атала?» (Савыт-саба.)

Тәрбияче балага йорт җиһазлары (караватъ, өстәл, урындык, шкаф) сурәтләнгән рәсемнәр күрсәтә һәм андагы предметларны атарга куша: «Бу нәрсә?» «Бу предметлар бер сүз белән ничек атала?» (Йорт җиһазлары.)

Тәрбияче балага йорт хайваннары (эт, песи, сыер, кәҗә) сурәтләнгән рәсемнәр күрсәтә һәм андагы предметларны атарга куша: «Бу нәрсә?» «Бу хайваннар бер сүз белән ничек атала?» (Йорт хайваннары.)

Тәрбияче балага кыргый хайваннар (куян, төлке, аю) сурәтләнгән рәсемнәр күрсәтә һәм андагы хайваннарны атарга куша: «Бу нәрсә?» «Бу хайваннар бер сүз белән ничек атала?» (Кыргый хайваннар.)

Тәрбияче балага киемнәр (күлмәк, куртка, башлык) сурәтләнгән рәсемнәр күрсәтә һәм предметларны атарга куша: «Бу нәрсә?» «Бу предметлар бер сүз белән ничек атала?» (Киемнәр.)

Бәяләү критерийлары

Бала, предметларның исемен атаганда, авырлыклар кичерә, гомумиләштерүче сүзләрне куллана белми — 1 балл;

предметларның исемен дөрес атый, гомумиләштерүче сүзләрне белдергәндә, хаталар җибәрә — 2 балл;

предметларның исемен дөрес атый, гомумиләштерүче сүзләрне дөрес билгели — 3 балл.

**2. СӨЙЛӘМНЕҢ ГРАММАТИК ЯГЫ**

**1. «Кем нәрсә эшли?» дидактик уены**

Материал: китап укучы әни, өреп торган эт, уйный торган малай, рәсем ясаучы кыз сурәтләнгән рәсемнәр.

Диагностик биремнең эчтәлеге

Тәрбияче балага китап укучы әни төшерелгән рәсем күрсәтә һәм сораулар бирә: «Бу кем?» (Әни.) «Әни нәрсә эшли?» (Укый.) «Әни нәрсә укый?» (Әни китап укый.)

Тәрбияче балага өреп торган эт төшерелгән сюжетлы рәсем күрсәтә һәм сораулар бирә: «Бу нәрсә?» (Эт.) «Эт нәрсә эшли?» (Эт өрә.) «Ул ничек өрә?» (Эт «һау-һау» дип өрә.)

Тәрбияче балага уйный торган малай төшерелгән рәсем күрсәтә һәм сораулар бирә: «Бу кем?» (Малай.) «Малайның исеме ничек?» (Бала малайга исем биреп карый.) «Малай нишли?» (Малай уйный.) «Ул нәрсә белән уйный?» (Ул машина белән уйный.)

Тәрбияче балага рәсем ясаучы кыз төшерелгән рәсем күрсәтә һәм сораулар бирә: «Бу кем?» (Кыз.) «Кызның исеме ничек?» (Бала кызга исем бирә.) «Кыз нәрсә эшли?» (Кыз рәсем ясый.) «Ул нәрсә белән рәсем ясый?» (Ул карандаш белән рәсем ясый.) «Кыз нәрсә рәсеме ясый?» (Кыз кояш рәсеме ясый.)

Бәяләү критерийлары

Бала биремнәрне үти алмый. Тәрбияченең сорауларына җавап бирә алмый. Тәрбияче актив ярдәм күрсәткәндә дә, бала хаталар ясый — 1 балл;

бала биремнәрне үтәргә тырыша, тәрбиячененң сорауларына бер сүз белән генә җавап бирә — 2 балл;

бала биремнәрне дөрес үти. Тәрбиячененң сорауларына җавап биргәндә, җөмләләрне грамматик яктан дөрес төзи. Җөмләләрнең иясе һәм хәбәре бар. Тәрбиячененң сорауларына теләп, ышанычлы итеп җавап бирә — 3 балл.

**3. АВАЗ КУЛЬТУРАСЫ**

**1. «Бу нәрсә? Ул ничек кычкыра?» дидактик уены**

Материал: ат, кәҗә, тавык, каз, карга рәсемнәре.

Диагностик биремнең эчтәлеге

Тәрбияче балага ат (кәҗә, тавык, каз, карга) рәсеме күрсәтә һәм сораулар бирә: «Бу нәрсә?» (Ат.) «Ат ничек кешни?» («Ми-һа-һай!») «Бу нәрсә?» (Кәҗә.) «Кәҗә ничек кычкыра?» («Ми-ки-ки!») «Бу нәрсә?» (Тавык.) Тавык ничек кыткылдый? («Кыт-кытыйк!») «Бу нәрсә?» (Каз.) «Каз ничек каңгылдый?» («Ка-ка-ка!») «Бу нәрсә?» (Карга.) «Карга ничек каркылдый?» («Кар-кар!»)

Бәяләү критерийлары

Бала 1—2 биремне генә үти ала — 1 балл;

бала биремнәрне тәрбияче ярдәме белән башкара, аның артыннан кабатлый — 2 балл;

бала биремнәрне теләп башкара. Аваз ияртемнәрен дөрес һәм ачык итеп әйтә — 3 балл.

**4. БӘЙЛӘНЕШЛЕ СӨЙЛӘМ**

**1. Сюжетлы рәсем буенча әңгәмә**

Материал: кар бабай ясаучы балалар сурәтләнгән сюжетлы рәсем.

Диагностик биремнең эчтәлеге

Тәрбияче балаларның игътибарын рәсемгә җәлеп итә һәм сораулар бирә: «Карагыз әле, Йомшаккай бик матур бер рәсем ясаган. Бу рәсемдә кемнәр ясалган? Балалар нәрсә эшлиләр? Рәсем сиңа ошыймы?»

**“Туган телдә сөйләшәбез”, 3-4 яшь**

| № | Баланың исеме, фамилиясе | Сүз байлыгы. Бу кем? Бу нәрсә? | Сөйләмнең грамматик ягы | | Уеннарда катнашу | Аваз культурасы | Бәйләнешле сөйләм | | Баллар | Дәрәҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Нәрсә эшли? | Нинди? | | Минем кебек әйт | Үзең турында сөйләү (Син кем?) | Рәсем буенча әңгәмә (Сорау-җавап) | | |

Икенче кече яшьтәгеләр төркемендә сөйләм телен үзләштерү дәрәҗәләренә диагностика

Диагностик биремнәр (ел башы)

**1. Баланың сүзлек запасы**

**1) Дидактик уен «Бу нәрсә?»**

Материал: савыт-саба, йорт җиһазлары, йорт хайваннары, кыргый хайваннар, киемнәр сурәтләнгән предметлы картинкалар.

Диагностик биремнең эчтәлеге:

Тәрбияче балага савыт-саба (тәлинкә, чынаяк, чәй тәлинкәсе, табак) сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм андагы предметларны атарга куша:

– Бу нәрсә? Бу предметларны бер сүз белән ничек атарга була? (Савыт-саба).

Тәрбияче балага йорт җиһазлары (карават, өстәл, урындык, шкаф) сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм андагы предметларны атарга куша:

– Бу нәрсә? Бу предметларны бер сүз белән ничек атарга була? (Йорт җиһазлары).

Тәрбияче балага йорт хайваннары (эт, песи, сыер, кәҗә) сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм андагы предметларны атарга куша:

– Бу нәрсә? Бу хайваннарны бер сүз белән ничек атарга була? (Йорт хайваннары).

Тәрбияче балага кыргый хайваннар (куян, төлке, аю) сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм андагы хайваннарны атарга куша:

– Бу нәрсә? Бу хайваннарны бер сүз белән ничек атарга була? (Кыргый хайваннар).

Тәрбияче балага киемнәр (күлмәк, куртка, башлык) сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм предметларны атарга куша:

– Бу нәрсә? Бу предметларны бер сүз белән ничек атарга була? (Киемнәр).

Бәяләү критерийлары

1 балл – предметларның исемен атаганда авырлыклар кичерә, гомумиләштерүче сүзләрне куллана алмый.

2 балл – предметларның исемен дөрес атый, гомумиләштерүче сүзләрне белдергәндә хаталар җибәрә.

3 балл – предметларның исемен дөрес атый, гомумиләштерүче сүзләрне дөрес билгели.

**2. Сөйләмнең грамматик ягы**

**1). Дидактик уен «Кем нәрсә эшли?»**

Материал: китап укучы әни, өрә торган эт, уйный торган малай, рәсем ясаучы кыз сурәтләнгән сюжетлы картинкалар.

Диагностик биремнең эчтәлеге:

Тәрбияче балага китап укучы әни төшерелгән сюжетлы картинка күрсәтә һәм сораулар бирә: Бу кем? (Әни). Әни нәрсә эшли? (Укый). Әни нәрсә укый? (Әни китап укый).

Тәрбияче балага өрә торган эт төшерелгән сюжетлы картинка күрсәтә һәм сораулар бирә: Бу нәрсә? (Эт). Эт нәрсә эшли? (Эт өрә). Ул ничек өрә? (Эт һау-һау дип өрә).

Тәрбияче балага уйный торган малай төшерелгән сюжетлы картинка күрсәтә һәм сораулар бирә: Бу кем? (Малай). Малайның исеме ничек? (Бала малайга исем биреп карый). Малай нәрсә эшли? (Малай уйный). Ул нәрсә белән уйный? (Ул машина белән уйный).

Тәрбияче балага рәсем ясаучы кыз төшерелгән сюжетлы картинка күрсәтә һәм сораулар бирә: Бу кем? (Кыз). Кызның исеме ничек? (Бала кызга исем биреп карый). Кыз нәрсә эшли? (Кыз рәсем ясый). Ул нәрсә белән рәсем ясый? (Ул карандаш белән рәсем ясый). Кыз нәрсә рәсеме ясый? (Кыз кояш рәсеме ясый).

Бәяләү критерийлары

1 балл – бала биремнәрне үти алмый. Тәрбиянең сорауларына җавап бирә алмый. Тәрбияче актив ярдәм күрсәткәндә дә, хаталар ясый.

2 балл – бала биремнәрне үтәргә тырыша, тәрбиянең сорауларына бер сүз белән генә җавап бирә.

3 балл – бала биремнәрне дөрес үти. Тәрбиянең сорауларына җавап биргәндә, җөмләләрне грамматик яктан дөрес төзи. Җөмләләрнең иясе һәм хәбәре бар. Тәрбиянең сорауларына теләп, ышанычлы итеп җавап бирә.

**3. Сөйләмнең аваз культурасы**

**1) Дидактик уен «Бу нәрсә? Ул ничек кычкыра?»**

Материал: ат, кәҗә, тавык, каз, карга сурәтләнгән картинкалар.

Диагностик биремнең эчтәлеге:

Тәрбияче балага ат (кәҗә, тавык, каз, карга) төшерелгән картинка күрсәтә һәм сораулар бирә:

-Бу нәрсә? (Ат). Ат ничек кешни? (Их-ха-ха).

- Бу нәрсә? (Кәҗә). Кәҗә ничек кычкыра? (Ме-е-е).

- Бу нәрсә? (Тавык). Тавык ничек кыткылдый? (Кыт-кыт).

- Бу нәрсә? (Каз). Каз ничек каңгылдый? (Ка-ка-ка).

- Бу нәрсә? (Карга). Карга ничек каркылдый ? (Кар-кар).

Бәяләү критерийлары

1 балл – бала 1-2 биремне генә үти ала.

2 балл – бала биремнәрне тәрбияче ярдәме белән башкара, аның артыннан кабатлый.

3 балл – бала биремнәрне теләп башкара. Аваз ияртемнәрен дөрес һәм ачык итеп әйтә.

**4. Бәйләнешле сөйләм**

**1) Сюжетлы рәсем буенча әңгәмә**

Материал: кар бабай ясаучы балалар сурәтләнгән сюжетлы рәсем.

Диагностик биремнең эчтәлеге:

– Карагыз әле, Йомшаккай бик матур бер рәсем ясаган. Бу рәсемдә кем ясалган? Балалар нәрсә эшлиләр? Рәсем сиңа ошыймы?

**Диагностик биремнәр (ел азагы)**

**1. Баланың сүзлек запасы**

**1) Дидактик уен «Бу нәрсә?»**

Материал: савыт-саба, йорт җиһазлары, йорт хайваннары, кыргый хайваннар, киемнәр сурәтләнгән предметлы картинкалар.

Диагностик биремнең эчтәлеге:

Тәрбияче балага савыт-саба (тәлинкә, чынаяк, чәй тәлинкәсе, чәйнек) сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм андагы предметларны атарга куша: Бу нәрсә? Бу предметларны бер сүз белән ничек атарга була? (Савыт-саба). Чәйнекнең борынын күрсәт. Хәзер чәйнекнең капкачын күрсәт. Чынаякның тоткасын күрсәт.

Тәрбияче балага йорт җиһазлары (карават, өстәл, урындык, шкаф) сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм андагы предметларны атарга куша: Бу нәрсә? Бу предметларны бер сүз белән ничек атарга була? (Йорт җиһазлары). Өстәлнең аякларын күрсәт. Урындыкның аркасын күрсәт. Шкафның ишеген күрсәт.

Тәрбияче балага йорт хайваннары (эт, песи, сыер, кәҗә) сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм андагы предметларны атарга куша: Бу нәрсә? Бу хайваннарны бер сүз белән ничек атарга була? (Йорт хайваннары). Этнең колакларын күрсәт. Песинең койрыгын күрсәт. Сыерның мөгезен күрсәт. Кәҗәнең сакалын күрсәт.

Тәрбияче балага кыргый хайваннар (куян, төлке, аю) сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм андагы хайваннарны атарга куша: Бу нәрсә? - Бу хайваннарны бер сүз белән ничек атарга була? (Кыргый хайваннар). – Куянның тәпиләрен күрсәт. –

Төлкенең борынын күрсәт. – Аюның гәүдәсен күрсәт.

Тәрбияче балага киемнәр (күлмәк, куртка, башлык) сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм предметларны атарга куша: – Бу нәрсә? – Бу предметларны бер сүз белән ничек атарга була? (Киемнәр). – Күлмәкнең җиңен (якасын, кесәләрен, сәдәфләрен) күрсәт.

Бәяләү критерийлары

1 балл – предметларның исемен, мөһим детальләрен, өлешләрен атаганда һәм күрсәткәндә авырлыклар кичерә, гомумиләштерүче сүзләрне куллана алмый.

2 балл – предметларның исемен дөрес атый, мөһим детальләрен, өлешләрен күрсәткәндә, гомумиләштерүче сүзләрне белдергәндә хаталар җибәрә.

3 балл – предметларның исемен, мөһим детальләрен, өлешләрен дөрес атый һәм күрсәтә, гомумиләштерүче сүзләрне дөрес билгели.

**«Бу кайчан була?» үстерешле уены**

Балаларга тәүлек өлешләре сурәтләнгән карточкалар күрсәтелә. Тәрбияче тәүлек өлешенә туры килгән күренешләрне атый һәм сорау бирә, балалар тиешле карточканы табалар.

1. Кояш чыга, әтәчләр кычкыра, балалар бакчага барырга жыена, әти-әниләр эшкә китәләр. - Бу кайчан була? Бу тәүлек өлешенә туры килгән карточканы табып күрсәтегез.

2. Кояш яктырак карый, күзләрен киңрәк ача, балалар урамда уйный, төшке аш ашыйлар. - Бу кайчан була? Шушы тәүлек өлешенә туры килгән карточканы табып күрсәтегез.

3. Кояш күзләрен йома, балалар бакчадан, эти-әниләр эштән өйләренә кайта, кичке аш ашыйлар, балалар «Тыныч йокы, нәниләр» тапшыруын карыйлар. - Бу кайчан була? Бу тәүлек өлешенә туры килгән карточканы табып күрсәтегез.

4. Кояш йоклый, ай яктырта, күк йөзендә йолдызлар яна, бар кешеләр дә йоклый. - Бу кайчан була? Бу тәүлек өлешенә туры килгән карточканы табып күрсәтегез.

Бәяләү критерийлары

1 балл – тәүлек өлешләрен аера белми.

2 балл – өстәмә сораулар биргәндә генә тәүлек өлешләрен аера һәм дөрес атый.

3 балл – тәүлек өлешләрен аера һәм дөрес атый.

**2. Сөйләмнең грамматик ягы**

**1) Дидактик уен «Кем нәрсә эшли?»**

Материал: уенчык песи (Йомшаккай), төрле кошлар һәм җәнлекләр сурәтләнгән картинкалар.

Диагностик биремнең эчтәлеге:

Тәрбияче балаларга Йомшаккай турында сөйли: «Безнең Йомшаккайның дуслары бик күп. Дусларының кем икәнен белергә телисезме? Ул аларның фотографияләрен алып килгән. (Тәрбияче бер һәм күп куяннар, үрдәкләр, колыннар, чебиләр, көчекләр, сыерлар, бәрәннәр сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм сораулар бирә: Бу нәрсә? (Бер куян сурәтләнгән картинка күрсәтә). (Куян). Бу нәрсә? (Куяннар сурәтләнгән картинка күрсәтә). (Куяннар). Башка картинкалар белән эш шушы рәвешле алып барыла.

Тәрбияче сөйләвен дәвам итә: «Йомшаккай кошлар һәм җәнлекләр белән качышлы уйнарга ярата. Сез күзләрегезне йомыгыз. Йомшаккай кача.» (Тәрбияче Йомшаккайны шкаф артына (эченә, өстенә, астына, янына) качыра. Балалар күзләрен ачалар, Йомшаккайны эзлиләр һәм аның кайда качканын әйтәләр. Мәсәлән: «Йомшаккай шкаф артына качкан».

Тәрбияче сөйләвен дәвам итә: «Җәнлекләр һәм кошларны әниләре эзләп килгән. Әйдәгез, әниләренә аларны табарга булышыйк». (Тавык сурәтләнгән картинка куела). Тавык (сыер, эт, ат, сарык, куян) нәрсәне алырга килгән? (Тавык чебине алырга килгән.) (Шул рәвешле куян куян баласын, сыер бозавын, эт көчеген, сарык бәрәнен, ат колынын таба).

Бәяләү критерийлары

1 балл – бала биремнәрне үти алмый. Тәрбияченең сорауларына җавап бирә алмый. Тәрбияче актив ярдәм күрсәткәндә дә бала хаталар ясый.

2 балл – бала биремнәрне үтәргә тырыша, тәрбияченең сорауларына бер сүз белән генә җавап бирә.

3 балл – бала биремнәрне дөрес үти. Тәрбияченең сорауларына җавап биргәндә, берлек һәм күплек сандагы исемнәрне, бәйлек сүзләрне (эченә, өстенә, астына, янына), кошлар һәм җәнлекләр,

аларның балалары атамаларын сөйләмдә дөрес куллана, җөмләләрне грамматик яктан дөрес төзи. Җөмләләрнең иясе һәм хәбәре бар. Тәрбияченең сорауларына теләп, ышанычлы итеп җавап бирә.

**3. Сөйләмнең аваз культурасы**

**1) Дидактик уен «Минем кебек әйт».**

Диагностик биремнең эчтәлеге:

Тәрбияче балага үзе әйткән сүзләрне игътибар белән тыңлап, нәкъ шулай итеп кабатларга куша һәм сорау бирә. Тәрбияче, әле бер, әле икенче авазны аерып, сүзләрне я кычкырып, я тыныч тавыш белән, я пышылдап әйтә. Мәсәлән: «Минем кебек әйт».

А: Аааалсу, ааат, кааааз, боткааа.

Ә: Әәәәмир, мәәәк, кәәәҗәәә.

О: ооон, йооорт, ооонык, кооолын.

Ө: өөөй, өөөстәл, көөөзге, көөөймә.

У: ууурман, ууенчык, куууян, кууурчак.

Ү: үүүлән, үүүрдәк, күүүбәләк, үүүрмәкүүүч.

И: Иииинсаф, ииипиии, тииен, машииина, әниии.

Бәяләү критерийлары

1 балл – бала кирәкле авазны ишетми, күп сүзләрне дөрес интонация белән әйтми, хаталар ясый.

2 балл – бала күп сүзләрне дөрес кабатлый, дөрес интонация белән әйтә, тәрбияче ярдәме белән кирәкле авазны әйтә.

3 балл – бала кирәкле авазны ишетә, кабатлый, аны мөстәкыйль рәвештә дөрес интонация белән әйтә.

**4. Бәйләнешле сөйләм**

1) Сораулар буенча әңгәмә. – Синең өйдә нинди уенчыкларың бар? Син алар белән ничек уйныйсың? Кем белән уйныйсың? Сюжетлы рәсем буенча әңгәмә.

Бәяләү критерийлары

1 балл – бала бер уенчыкны гына атый.

2 балл – бала уенчыкларны санап кына чыга.

3 балл – бала үзенең шәхси тәҗрибәсенә нигезләнеп. 3-4 җөмләдән торган хикәя төзи.

2) Тәрбияче балага Л.Толстойның «Өч аю» әкиятен сөйләргә тәкъдим итә. – Син «Өч аю» әкиятен беләсеңме? Аны сөйлә әле.

Бәяләү критерийлары

1 балл – бала әкият эчтәлегенә кагылышлы кайбер сүзләрне генә әйтә ала.

2 балл – бала тәрбияче биргән сораулар ярдәмендә генә әкиятнең эчтәлеген сөйли.

3 балл – бала әкиятнең эчтәлеген мөстәкыйль сөйли ала.

Югары дәрәҗә - 15-18 балл.

Уртача дәрәҗә - 11-14 балл.

Түбән дәрәҗә - 7-10 балл

**“Туган телдә сөйләшәбез”, 4-5 яшь**

| № | Баланың исеме, фамилиясе | Сүз байлыгы | | Бәйләнешле сөйләм | | | | Иллюстрациягә карап әсәрнең исемен атау | Нәтиҗә | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Ягымлы сүзләр куллану | Боерыкны куллана белү | Үзең турында сөйләү | Нинди? Нишли? соравына җавап бирү | Уенчыклар санау (Ничә?) | Аралаша белү (диалог) | | Баллар | Дәрәҗә |

**Эчтәлек үзләштерү дәрәҗәләре:**

**Югары** – сөйләм осталыгына ия; әкиятләр, хикәяләр уйлап чыгарганда инициатива, мөстәкыйльлек күрсәтә (хикәянең структурасы турында күзаллаулары бар), башкаларның хикәяләрен кабатламый, сәнгатьлелекнең төрле чараларын куллана; эчтәлек сөйләгәндә, башы, уртасы, ахыры кебек текстның структур өлешләрен төгәл саклап, текст эчтәлеген эзлекле итеп бирә; сүзлек запасы бай; сөйләме сәнгатьле, грамматик яктан дөрес.

**Уртача** – үзе уйлап чыгарганда, хикәяне тасвирлаганда, әдәби әсәрләрнең эчтәлеген сөйләгәндә, төшереп калдырулар урын алып тора, логик хаталар җибәрә, ләкин тәрбияче ярдәмендә ул аларны үзе төзәтә; бик актив булмаса да, сөйләмдә аралашуга кызыксынуы бар; җөмлә төзегәндә кыенлыкларга очрамый, грамматик хаталар сирәк була; сөйләмнең сәнгатьлелеге җитәрлек дәрәҗәдә түгел.

**Түбән** – эчтәлек сөйләгәндә бәйләнешләр урнаштыруда кыенлыклар кичерү сәбәпле, мәгънәсе һәм эчтәлеге буенча хаталар җибәрә, сөйләү барышында тәрбияче ярдәменә мохтаҗ; үзе әкиятләр, хикәяләр, кызыклы хәлләр турында сөйләгәндә, тасвирламалар төзегәндә структур өлешләрне төшереп калдыра, мөстәкыйльлеге дә җитәрлек түгел (иптәшләренең хикәяләрен кабатлый); сүзлек запасы ярлы; грамматик хаталар җибәрә; сөйләме сәнгатьле түгел.

**“Туган телдә сөйләшәбез”, 5-6 яшь**

| № | Баланың исеме, фамилиясе | Сүз байлыгы | | | Бәйләнешле сөйләм | | | Фольклор (мәкаль, санамыш, табышмак, әкиятләр) | Нәтиҗә | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Ягымлы сүзләр куллану | Сүзләрне гомумиләштерү | Капма-каршы сүзләр | Үзең турында сөйләү | “Уйный-уйный үсәбез” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану | Аралаша белү (диалог) | | Баллар | Дәрәҗә |

| Танып белү | Аралашу | Матур әдәбият уку |
|---|---|---|
| - транспорт төрләрен кеше тормы шын җиңеләйтә, уңайлыклар тудыра торган әйберләрне белү;<br>- предметның төсе, күләме, формасы, зурлыгы, авырлыгы, нинди материалдан | - сөйләмдә төрле кушма җөмләләр куллану, туры һәм кыек сөйләмнән файдалану;<br>- үз тәҗрибәсеннән чыгып, эчтәлекле рәсемнәр, картиналар буенча | - әсәрнең жанрын билгели алу (әкият, хикәя, шигырь);<br>- зур булмаган әсәрләрне сәхнәләштерү, рольләргә бүлеп шигырьләрне сөйләү; |

| | | |
|---|---|---|
| эшләнгән булуы турында сөйли алу, аларны төркемләү;<br>- төрле һөнәрләр (төзүчеләр, авыл эшчәннәре һ.б.) турында белү;<br>- туган шәһәрең (авылың), туган илең, аның башкаласы, юл йөрү кагыйдәләрен белү;<br>- үз туганнары, үзе турында сөйли алу, өй адресын әйтү;<br>- табигать күренешләрен күзәтеп, алар арасындагы бәйләнешләр турында нәтиҗә чыгара алу, кайбер закончалыкларны белү. | мөстәкыйль рәвештә хикәя төзү;<br>- әкиятләрнең ахырын тәмамлау, зур булмаган әдәби әсәрләрнең эчтәлеген сөйләгәндә интонацияләрдән дөрес файдалану;<br>- сөйләмдә, башкалар белән аралашканда ягымлы сүзләр куллану;<br>- мәгънәдәш сүзләр һәм капма-каршы сүзләр куллану;<br>- аралашуда актив булу, теләп катнашу. | - яраткан язучыларны атый белү;<br>- укыту методик комплектында күрсәтелгән 2 – 3 шигырьнесөйләү, табышмак, мәкальләрне искә төшереп әйтү;<br>- әдәби персонажның кылган гамәлләре турындагы фикерләрен башкаларга сөйләү;<br>- үзенең яраткан китабы турында башкаларга сөйли белү. |

**Танып белү**

**Югары дәрәҗә (3 балл).** Бала транспорт төрләрен, кеше тормышын җиңеләйтә, уңайлыклар тудыра торган әйберләрне таный һәм әйтә. Предмет һәм аның үзенчәлекләре (төсе, формасы, күләме, нинди материалдан булуы) турында сөйли, аларны төркемли белә. Төзүче, транспорт хезмәткәрләре, авыл эшчәннәре хезмәте турында белә. Юл йөрү кагыйдәләрен дөрес әйтә. Туган иле, шәһәре (авылы), Россиянең, Татарстанның башкаласы турында белә. Үз туганнары, үзе турында сөйли, адресын әйтә. Табигатьтәге кайбер закончалыкларны белә, алар арасындагы бәйләнешләр турында нәтиҗә чыгара.

**Уртача дәрәҗә (2 балл).** Бала транспорт төрләрен, кеше тормышын җиңеләйтә, уңайлыклар тудыра торган әйберләрне атаганда хата җибәрә, ләкин үзлектән төзәтә. Предмет һәм аның үзенчәлекләре (төсе, формасы, күләме, нинди материалдан булуы) турында тулысынча сөйләми, исенә төшергәч, өстәп сөйли белә, төркемли ала. Төзүче, транспорт хезмәткәрләре, авыл эшчәннәре хезмәте турында мәгълүматны тулысынча биреп бетерә алмый. Туган иле, шәһәре (авылы), Россиянең, Татарстанның башкаласы турында белә. Үз туганнары, үзе турында аз сөйли, сораулар биргәч, үзлектән тулыландыра. Табигатьтәге кайбер закончалыкларны аңлатканда, үзара бәйләнешләр турында нәтиҗә чыгарганда кыенлыклар кичерә.

**Уртачадан түбән дәрәҗә (1 балл).** Бала транспорт төрләрен, кеше тормышын җиңеләйтә, уңайлыклар тудыра торган әйберләрне атаганда хата җибәрә. Предмет һәм аның үзенчәлекләре (төсе, формасы, күләме, нинди материалдан булуы) турында тәрбияче ярдәменнән башка сөйли белми, төркемли алмый. Төзүче, транспорт хезмәткәрләре, авыл эшчәннәре хезмәте турында мәгълүматы юк. Туган иле, шәһәре (авылы), Россиянең, Татарстанның башкаласы турында әйтә белми. Үз туганнары, үзе турында тәрбияче ярдәмендә сөйли. Адресын белми. Табигатьтәге кайбер закончалыкларны аңлата, үзара бәйләнешләр турында нәтиҗә чыгара алмый.

**Аралашу**

**Югары дәрәҗә (3 балл).** Сөйләмдә төрле кушма җөмләләр куллана белә, туры һәм кыек сөйләмнән файдалана. Үз тәҗрибәсеннән чыгып, эчтәлекле рәсемнәр, картиналар буенча мөстәкыйль рәвештә хикәя төзи. Әдәби әсәрләрнең эчтәлеген сөйләгәндә, иҗади хикәяләр төзегәндә интонацияләрдән дөрес файдалана. Сөйләмдә, башкалар белән аралашканда ягымлы

сүзләр куллана белә. Мәгънәдәш сүзләр, капма-каршы сүзләрне дөрес әйтә белә. Тәрбияче һәм балалар белән аралашуда теләп катнаша. Үстерешле аралашуда катнашу дәрәҗәсе камил.

**Уртача дәрәҗә (2 балл).** Сөйләмдә төрле кушма җөмләләр кулланганда хаталар җибәрә, үзлектән төзәтә белә. Үз тәҗрибәсеннән чыгып, эчтәлекле рәсемнәр, картиналар буенча хикәя төзегәндә тәрбияче ярдәмен көтә, бик үк мөстәкыйль түгел. Әдәби әсәрләрнең эчтәлеген тулы бирми, иҗади хикәяләр төзегәндә иҗади түгел. Сөйләмдә, башкалар белән аралашканда, ягымлы сүзләрне аз куллана. Мәгънәдәш сүзләр, капма-каршы сүзләрне әйткәндә хаталар җибәрә. Тәрбияче һәм балалар белән аралашуда катнаша, үстерешле аралашуда катнашуы камил дәрәҗәдә түгел.

Ур**тачадан түбән дәрәҗә (1 балл).** Бала сөйләмдә гади җөмләләр куллана, үз тәҗрибәсеннән чыгып, начар сөйли, эчтәлекле рәсемнәр, картиналар буенча хикәя төзегәндә тәрбияче ярдәмен көтә. Әдәби әсәрләрнең эчтәлеген план буенча сөйли белми, иҗади хикәяләренең эчтәлеге гади, интонацияләрдән файдаланмый. Сөйләмдә, башкалар белән аралашканда ягымлы сүзләрне аз куллана. Мәгънәдәш сүзләр, капма-каршы сүзләрне әйтми. Тәрбияче һәм балалар белән аралашуда сирәк катнаша, үстерешле аралашуда катнашуы юк дәрәҗәдә.

**Матур әдәбият уку**

**Югары дәрәҗә (3 балл).** Әсәрнең жанрын (әкият, хикәя) аера ала. Зур булмаган әсәрләрне сәхнәләштерүдә, рольләргә бүлеп шигырьләр укуда актив катнаша, тиз истә калдырып, яттан сөйли. Язучыларны таный һәм атый, әсәрләрен белә. Шигырьләрне, мәкальләрне, санамышларны сөйләмдә мөстәкыйль куллана. Әдәби персонажларның кылган гамәлләренә дөрес бәя бирә. Үзенең яраткан китабы турында башкаларга сөйләп бирә ала.

**Уртача дәрәҗә (2 балл).** Әсәрнең жанрын (әкият, хикәя) аергандa ялгышлыклар җибәрә, ләкин тәрбияче ярдәмендә үзлектән төзәтә ала. Зур булмаган әсәрләрне сәхнәләштерүдә, рольләргә бүлеп шигырьләр укуда активлык күрсәтми, ләкин катнаша. Язучыларны таный, әсәрләрен әйтүдә кыенлыклар кичерә. Шигырьләрне, мәкальләрне, санамышларны сирәк куллана. Әдәби персонажларның кылган гамәлләренә бәя биргәндә, хаталар җибәрә. Үзенең яраткан китабы турында башкаларга тулы итеп сөйләми.

**Уртачадан түбән дәрәҗә (1 балл).** Әсәрнең жанрын (әкият, хикәя) аера алмый. Зур булмаган әсәрләрне сәхнәләштерүдә, рольләргә бүлеп шигырьләр укуда катнашырга теләге юк. Язучыларны танымый, әсәрләрен әйтә алмый. Шигырьләрне, мәкальләрне, санамышларны кулланмый. Әдәби персонажларның кылган гамәлләренә бәя бирә белми. Үзенең яраткан китабы турында башкаларга сөйли белми.

**“Туган телдә сөйләшәбез”, 6-7 яшь**

| № | Баланың исеме, фамилиясе | Сүз байлыгы | | | Бәйләнешле сөйләм | | | Фольклор (мәкаль, санамыш, табышмак, әкиятләр) | Нәтиҗә | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Ягымлы сүзләр куллану | Сүзләрне гомумиләштерү | Капма-каршы сүзләр | Үзең турында сөйләү | Рәсем буенча сөйләү | Аралаша белү (диалог) | | Баллар | Дәрәҗә |

| Танып белү | Аралашу | Матур әдәбият уку |
|---|---|---|
| - сәламәт яшәү рәвеше, дөрес туклану турында күзаллау;<br>- экологик бәйләнешләрне аңлата алу, кешенең табигать белән бәйләнеше, үзара йогынтысын белү;<br>- табигатьнең төрлеобъектлары турында мәгълүматлы булу;<br>- предметларны үзләренә генә хас билгеләре, Үзенчәлекле сыйфатлары буенча аерып ала һәм төркемли белү;<br>- үзе, эти-әнисе турында сөйли белү (фамилиясен, исемен, этисенеңисемен, адресын, телефон номерын әйтә алу), өлкәннәр хезмәте, аларның эшлекле сыйфатлары турында мәгълүматлы булу. | - күмәк сөйләмдә катнашу (сораулар бирә, сорауларга тулы җавап кайтара, вакыйгалар, фактлар, күренешләр турында эзлекле, мәгънәле һәм аңлаешлы итеп сөйли);<br>- сөйләмдә төрле сүз төркемнәрен мәгънәсе буенча аңлап, төгәл куллану;<br>- сүзләрне контексттагы мәгънәсенә туры китереп сөйли белү күнекмәләре булу;<br>- предметлар, картиналар, рәсемнәр буенча, үз тәҗрибәсеннән чыгып, иҗади хикәяләр төзи белү;<br>- тәрбияче һәм яшьтәшләре белән әдәпле итеп сөйләшә белү. | - әсәрнең жанрын билгели алу (әкият, хикәя, шигырь);<br>- китап геройларының хәленә керә белү, кылган гамәлләренә дөрес бәя бирү, үз мөнәсәбәтен белдерү;<br>- шигырьләрне, сәхнәләштергән әсәрләрне сәнгатьле итеп сөйләү, эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирә белү;<br>- иллюстрацияләр, рәсемнәргә карап, өйрәнгән матур әдәбият әсәрләрен тану;<br>- китаплардан яңа белемнәр алу мөмкинлеген аңлау. |

**Танып белү Югары дәрәҗә (3 балл).** Бала сәламәт яшәү рәвеше, дөрес туклану турында күзаллый. Экологик бәйләнешләрне аңлата ала, кешенең табигать белән бәйләнеше, үзара йогынтысын белә. Табигатьнең төрле объектлары турында мәгълүмат бирә ала. Предметларның үзләренә генә хас билгеләре, үзенчәлекле сыйфатлары турында сөйли, аларны төркемли белә. Үзе, эти-әнисе турында сөйли белә (фамилиясен, исемен, этисенең исемен, адресын, телефон номерын әйтә ала), өлкәннәр хезмәте, аларның эшлекле сыйфатлары турында мәгълүматы бар.

**Уртача дәрәҗә (2 балл).** Сәламәт яшәү рәвеше, дөрес туклану турында баланың күзаллавы җитәрлек дәрәҗәдә түгел. Экологик бәйләнешләрне күрүдә авырыксына, тәрбияче яки балалар ярдәмендә үзе җавап бирә. Табигатьнең төрле объектлары турында мәгълүматы бар, дөрес итеп тәрбияче ярдәмендә аңлата. Предметларның үзләренә генә хас билгеләре, үзенчәлекле сыйфатлары турында сөйләгәндә хаталар җибәрә, төркемләгәндә хаталар җибәрсә, үзлектән төзәтә белә. Үзе (фамилиясе, исеме,этисенең исеме, адресы, телефон номеры, эти-әнисе) турындамәгълүматы тулы түгел.

**Уртачадан түбән дәрәҗә (1 балл).** Сәламәт яшәү рәвеше, дөрес туклану турында бала күзалламый. Экологик бәйләнешләрне, кешенең табигать белән бәйләнеше, үзара йогынтысы турында әйтә белми. Табигатьнең төрле объектларытурында мәгълүмат бирә алмый. Предметларның үзләренә генә хас билгеләре, үзенчәлекле сыйфатлары турында сөйли, әмма аларны төркемләми. Үзе (фамилиясе, исеме, әтисенең исеме,адресы, телефон номеры, әти-әнисе) турында мәгълүматы аз.

**Аралашу Югары дәрәҗә (3 балл).** Бала күмәк сөйләмдә актив катнаша (сораулар бирә, сорауларга тулы җавап кайтара, вакыйгалар, фактлар, күренешләр турында эзлекле, мәгънәле, аңлаешлы итеп сөйли). Сөйләмдә төрле сүз төркемнәрен мәгънәсе буенча аңлап, төгәл куллана ала. Сүзләрне контексттагы мәгънәсенә туры китереп сөйли белә. Предметлар, картиналар, рәсемнәр буенча, үз тәҗрибәсеннән чыгып, үзлектән иҗади хикәяләр төзи белә. Тәрбияче һәм яшьтәшләре белән әдәпле итеп сөйләшә белә. Бәйләнешле сөйләме чиста, грамматик яктан дөрес.

**Уртача дәрәҗә (2 балл).** Бала күмәк сөйләмдә катнаша (сорауларны аз бирә, сорауларга җавап кайтара, вакыйгалар, фактлар, күренешләр турында эзлекле сөйләгәндә хаталар җибәрә, ләкин үзлектән төзәтә). Сөйләмдә төрле сүз төркемнәрен мәгънәсе буенча кулланганда хаталар җибәрә. Предметлар, картиналар, рәсемнәр буенча, үз тәҗрибәсеннән чыгып иҗади хикәяләр төзегәндә, хаталар җибәрә, тәрбияче ярдәмендә үзлектән төзәтә ала. Тәрбияче һәм яшьтәшләре белән әдәпле итеп сөйләшә белә.

**Уртачадан түбән дәрәҗә (1 балл).** Бала күмәк сөйләмдә катнашмый (сораулар бирә, сорауларга тулы җавап кайтара алмый; вакыйгалар, фактлар, күренешләр турында эзлекле сөйләгәндә хаталар җибәрә, үзлектән төзәтә белми). Сөйләмдә төрле сүз төркемнәрен мәгънәсе буенча кулланганда хаталар җибәрә. Предметлар, картиналар, рәсемнәр буенча, үз тәҗрибәсеннән чыгып, үзлектән иҗади хикәяләр төземи.

**Матур әдәбият уку Югары дәрәҗә (3 балл).** Әсәрнең жанрын билгели ала (әкият, хикәя, шигырь). Китап геройларының хәленә керә белә, кылган гамәлләренә дөрес бәя бирә, үз мөнәсәбәтен белдерә. Шигырьләрне, сәхнәләштерелгән әсәрләрне сәнгатьле итеп сөйли, эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирә белә. Иллюстрацияләр, рәсемнәргә карап, өйрәнгән матур әдәбият әсәрләрен таный. Китаплардан яңа белемнәр алу мөмкинлеген аңлый.

**Уртача дәрәҗә (2 балл).** Әсәрнең жанрын билгеләүдә (әкият, хикәя, шигырь) хаталар җибәрә. Китап геройларының хәленә керә белә, кылган гамәлләренә дөрес бәя бирә, үз мөнәсәбәтен аңлата алмый. Шигырьләрне, сәхнәләштергән әсәрләрне сөйләгәндә, сәнгатьлелек җитми. Эчтәлеге буенча сорауларга җавап биргәндә, хаталар җибәрә. Иллюстрацияләр, рәсемнәргә карап, өйрәнгән матур әдәбият әсәрләрен таныганда, хаталар җибәрә, күп очракта үзлектән төзәтми. Китаплар белән кызыксына, мөстәкыйльлеге чамалы.

**Уртачадан түбән дәрәҗә (1 балл).** Бала әсәрнең жанрын (әкият, хикәя, шигырь) тәрбияче ярдәменнән башка билгели алмый. Китап геройларының хәленә керә белми, кылган гамәлләренә дөрес бәя бирә алмый, үз мөнәсәбәтен дөрес аңлата алмый. Шигырьләрне тиз истә калдырмый, сәхнәләштергән әсәрләрне сөйләгәндә, сәнгатьлелеге, иҗадилыгы юк. Эчтәлеге буенча сорауларга тәрбияче ярдәмендә җавап бирә яки бирә алмый. Иллюстрацияләр, рәсемнәргә карап, өйрәнгән матур әдәбият әсәрләрен таныганда, күп хаталар җибәрә. Китаплар белән кызыксынмый.

**“Татарча сөйләшәбез” “Минем өем” проекты, 4-5 яшь.**

| № | Баланың исеме, фамилиясе | Сүз байлыгы | | Бәйләнешле сөйләм | | | Балл | Дәрәҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Өйрәнгән темалар буенча 5-6 рәсем, предмет күрсәтергә. Татарча исемнәрен әйтергә кушыла. | Ягымлы сүзләр куллану (Исәнме, сау бул, рәхмәт) | Боерыкны аңлап үтәү һәм куллана белү (кил, утыр, сикер, ю, аша, эч.) | Тирә-юньдәге предметларның күләмен сыйфатын, күләмен белдерә торган сүзләрне аңлап сөйләмдә куллану | Аралаша белү (ягымлы сүзләр, әйтү, чакыру, сыйлау,сорап алу, тәкъдим итү, раслау) | | |

**“Татарча сөйләшәбез” “Уйный-уйный үсәбез” проекты, 5-6 яшь.**

| № | Баланың исем, фамилиясе | **Сүз байлыгы** | | **Бәйләнешле сөйләм** | | | **Нәтиҗә** | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | “Уйный – уйный үсәбез” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану. (Өйрәнгән темалар буенча биш – алты рәсем яисә предмет күрсәтелә, татарча исемнәрен әйтергә кушыла) | Ягымлы сүзләр куллану (“исәнме”, “сау бул”, “рәхмәт”. “исәнмесез”, “сау булыгыз”) | Боерыкны бирә белү (кил, утыр, сикер, уйна, ю, аша, эч, ки, сал) | Уен ситуацияләрендә үзлектән сорау бирә белү (Нәрсә кирәк? Нинди? | Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сорап алу, тәкъдим итү, | Баллар | Дәрәҗә |

**“Татарча сөйләшәбез”**
**“Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар” проекты, 6-7 яшь**

| № | Баланың исеме, фамилиясе | Сүз байлыгы | | Бәйләнешле сөйләм | | | Бала | Дәрәҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Өйрәнгән темалар буенча 5-6 рәсем, предмет күрсәтергә. Татарча исемнәрен әйтергә кушыла. | Ягымлы сүзләр куллану (Исәнме, сау булыгыз, хәлләр ничек? рәхмәт, зур рәхмәт, хәерле көн, әйбәт) | Боерыкны аңлап үтәү һәм куллана белү (кил, утыр, уйна,сикер, ю, аша, ки, сал, йөгер, бие, җырла,йокла,эч.) | Уен ситуацияләрендә үзлектән сораулар бирә белү (Нәрсә кирәк?Нинди? Ничә? Син кем?Бу нәрсә?Нишли?Нишлисең?) | Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау,сорап алу, тәкъдим итү, инкарь итү,раслау) | | |